• VIII КОРЫЛТАЙ •

КАЗАНДА ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕНЕҢ VIII КОРЫЛТАЕ УЗДЫ

4-5 бит

• РАМАЗАН •

РАМАЗАН – КАДЕРЛЕ КУНАК

7 бит

• ӘҢГӘМӘ•

"ТЕЛЛӘР ӨЙРӘТҮ – ИЗГЕ ЭШ"

10 бит

• НӘСЫЙХӘТ•

РАМАЗАН АЕ ХАТИРӘЛӘРЕ

12 бит

№ 4 (309) Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы Рамазан-шәүвәл 1442

апрель, 2021

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

Мөселманнар өчен айлар арасында Рамазан ае, көннәр арасында җомга көне, кичләр арасында Кадер кичәсе иң мөбарәк санала. Кадер кичәсе Рамазан-шәриф аенда булган бер кичәдер. Шул ук вакытта Рамазанның кайсы кичәсендә булганы төгәл һәм ачык рәвештә билгеләнмәгән. Бу мәсьәләдә галимнәр төрле фикердә.

Дәвамы 7 нче биттә

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

Нәзарәтнең “Зәкят” фонды мохтаҗлар өчен фидия җыюны игълан итте

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең “Зәкят” хәйрия фонды, алга таба халыкның мохтаҗ катламнарына бүлеп бирү максатыннан, «Рамазан – изге гамәлләр ае» дип исемләнгән хәйрия марафоны кысаларында халыктан фидия җыя башлады. Җыелган акчаларны фонд хезмәткәрләре мохтаҗ гаиләләргә таратып бирәчәк. Фидияне “Зәкят” фондында 13 майга кадәр кабул итәчәкләр.

Нәзарәтнең Голәмәләр һәм Казыйлар шурасы фидияне 200 сум күләмендә билгеләде. Аны сәламәтлек торышына бәйле рәвештә ураза тоту мөмкинлегенә ия булмаган һәм аны башка вакытта да каза кылып үти алмаучылар түли.

Фидияне ике юл белән күчерергә мөмкин:

1. 5336 6902 2342 7776 номерлы Саклык банкы картасы («Зәкят» фонды хезмәткәре Вәлиуллова Гүзәлия Галимҗан кызы исемендә).

2. Оешманың тулы исеме «Зәкят» хәйрия фонды.

Кыскартылган исеме «Зәкят» фонды.

Генераль директор – Мәрданов Булат Раиф улы
ИНН 1655068682
КПП 165501001
ОГРН 1091600003153
Банк ПАО «Ак барс» банк
К/с 30101810000000000805
Р/с 40703810400020000071
БИК 049205805
Юридик адрес: 420111, ТР, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт.
Гамәлдәге адрес: 420021, ТР, Казан шәһәре, Тукай урамы, 89 нчы йорт.
Телефон: 89872253322.
Сайт: www.zakyatrt.ru
e-mail: fondzakyat@yandex.ru

Акча күчерүнең максатында «Фидия» дип күрсәтергә.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

Мөфти Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчелеге белән очрашты

16 нчы апрельдә Нәзарәткә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров һәм Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесенең РФ төбәкләрендәге татар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү буенча урынбасары Марс Тукаев килде. Мөхтәрәм кунаклар җомга намазыннан соң Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән очрашты.

Данис Шакиров Татарстан Республикасы вице-премьеры, Бөтендөнья татар конгрессы Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев исеменнән Камил хәзрәт Сәмигуллинны яңа срокка мөфти итеп сайлануы белән тәбрикләде, аңа шәрәфле кунакларга бирелә торган истәлекле бүләк – кул сәгате бүләк итте.

Алга таба очрашуда катнашучылар XI “Милли тормыш һәм дин” Бөтенрәсәй татар дин әһелләре форумына әзерлек буенча фикер алышты.

Данис Шакиров әлеге чараның якынча программасы белән таныштырды, оештыру мәсьәләләренә, эчтәлегенә тукталды. Эшлекле сөйләшүдә катнашучылар секция утырышларын алып бару тәртибенә, төп темаларга тукталды, чакырылачак спикерлар, дин белгечләре, экспертларны чакыру буенча фикер алышты.

Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчелеге Татарстан мөселманнарының VIII Корылтаен югары дәрәҗәдә уздыруны билгеләп үтте, соңгы 4 еллыкта эш нәтиҗәләре тасвирланган, татар-мөселман гореф гадәтләренә нигезләнеп төзелгән “ӘМАНӘТ” күргәзмәсенә сокланулар белдерде: “Бик зур яңалыклар белән танышып кайттык. Халкыбызны дини һәм милли тәрбияләү өлкәсендә зур эш башкарасыз. Татар халкының сезнең кебек белемле, булдыклы, зирәк мөфтие барлыкка килүенә сокланабыз. Сезгә рәхмәт сүзеннән башка бер сүзебез дә юк”, – диде Данис Шакиров. Ул дин әһелләре форумын уздырганда нәзарәтнең зур тәҗрибәсе файдаланылачагын искәртте. Аерым алганда, рухи мирасны кайтару, Коръәннәр һәм дини китаплар нәшер итү һәм эшчәнлекнең башка юнәлешләрен дин әһелләре форумы делегатларына тәкъдим итү ышанычын белдерде.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

“Рамазан – изге гамәлләр ае” марафоны: авыру балаларга ничек ярдәм итәргә?

Татарстанда «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны колач җәя.

Аның бер юнәлеше 5 авыру балага тернәкләнү өчен акча җыюны күздә тота. Аларга садака рәвешендә акча күчерүнең 3 ысулы булдырылды: акчаны смс белән, банк картасына яки реквизитлар аша җибәрергә мөмкин. Әйтергә кирәк, былтыр әлеге акция кысаларында 12 сабыйга дәвалану курсларын узу өчен мөмкинлек тудырылды. Быелгы Рамазан аенда әлеге балаларга ярдәм итү мөмкинлеге каралган:

Ярдәмгә мохтаҗ беренче бала – **Мәрьям Хәйретдинова.** Аңа 7 яшь. Үзе кечкенә булса да, диагнозлар исемлеге зур: сабыйда ачык булмаган этиологияле энцефалопатия, баш миендә арахноидаль киста, йөрәге тумыштан тайпылышлы һәм операция ясалган, психосәйләм үсеше тоткарлану... Мәрьям үз гомерендә 6 операция кичергән. Шуларның икесе – баш миенә, бер операция – йөрәккә. Шулай ук сукыр эчәгесен, остеомиелитны дәвалау һ.б. Тормышы катлаулы булуга карамастан, Мәрьям гел үсештә. 7 яшендә кыз гадәти гимназиягә укырга керә. Балага тернәкләнү курслары таләп ителә. Мәрьямгә моның өчен 60 000 сум акча кирәк.

Ярдәмгә мохтаҗ икенче бала – **Динә Галиуллина.** Аңа 12 яшь. Сабыйда спастик тетрапарез, күзләрнең челтәр катлавы астегматизмы. Динә 28 нче атнада туган. Биш айда аңа диагноз куйганнар. 2 айда кызның күзенә операция ясаганнар. Ул бары тик 2 яшьтә генә утыра башлаган. Өч яшьтә генә, әти-әниләрен сөендереп, бераз сөйләшергә тотынган. Гаиләдә әтиләре генә эшли. Шуңа күрә акча бик кирәк әйберләргә генә җитә. Хәзер сабыйга тернәкләндерү курслары бик кирәк. Әмма бу курслар өчен гаиләнең түләргә көче җитми. Алар безнең ярдәмгә мохтаҗ. Динәне аякка бастыру өчен 60 000 сум акча кирәк.

Ярдәмгә мохтаҗ өченче бала – **Айзат Билаловка** 4 яшь. Диагнозы: ДЦП, спастик тетрепарез, Веста синдромы. Ул бу дөньяга бик авырдан килә. Баланы тартып диярлек алалар, ул зәңгәрләнгән була һәм бары 20 минуттан соң гына кычкырып җибәрә. Айзат үзе сулый алмаган, бары зонд аша гына ашаган. Берникадәр вакыттан соң аны көзән җыера башлый, өстәвенә Веста синдромы да бар. Малай ятып кына тора, әйләнми, сөйләшми... Балага кичекмәстән тернәкләнү узарга кирәк. Айзат тулы гаиләдә тәрбияләнә, әмма әтиләре генә эшли. Әнисе авыру баланы тәрбияләү белән мәшгуль һәм тагын бер бәби көтә. Айзат өчен кирәк булган акча – 60 000 сум.

Ярдәмгә мохтаҗ дүртенче бала – **Семён Матвеев.** 8 яшьлек Семён гаиләдә өченче бала булып туган, ир-балалардан берүзе ул. Әнисенең йөклелек чоры яхшы уза, Семённы гаиләдә зарыгып көтәләр. Бала дөньяга килгән вакытта, аның йөрәге тибүдән туктый. Малайның хәле бик авыр була. Шуннан соң Семён күпсанлы тернәкләнү курслары уза, дәвалана. Хәзер Сёма мөстәкыйль рәвештә басып йөри алырлык хәлдә түгел. Ул барысын да аңлый, сөйләшә, кулга тотынып йөри. Тиздән катлаулы операция ясарга тиешләр, аннан соң кабаттан тернәкләнү курслары узарга кирәк булачак. Семён өчен 60 000 сум күләмендә акча җыю игълан ителә.

Ярдәмгә мохтаҗ бишенче бала **Вика** исемле. Аңа 12 яшь, ул 4 нче мәктәп-интернатта укый. Туган вакытта табиб хатасы белән Викага нык зыян килә. Алты айлык чагында аңа балалар церебраль параличы, спастик тетрапарез диагнозы куела. Виктория бик авырлык белән йөри, гиперкинезлар (авыруның үз ихтыярыннан башка барлыкка килә торган хәрәкәтләр) бар, күз күреме начар, яза алмый, зур булмаган араларга тотынып кына йөри. Вика биш аеннан бирле даими рәвештә тернәкләндерү курслары уза. Өйдә ул шулай ук сәламәтләндерү физкультурасы белән шөгыльләнә, массаж ала, логопед, репетитор һәм дефектолог белән шөгыльләнә. Тырышлык бушка узмый: Вика сөйләшә, бер кул белән тотынып һәм ходунки белән йөри башлый. Әниләре бары балаларны карау белән генә шөгыльләнә, гаиләдә әти кеше генә эшли. Гаиләнең шактый кыймммәт торган курсларга акчасы җитми. Алар ярдәм сорый. Кирәк булган сумма – 60 000 сум.

Әлеге балаларга ярдәм итүнең 3 юлы бар:

1) 3116 номерына kazan сүзен язып смс-хәбәр җибәрергә.

2) 6390 0262 9014 6262 29 номерлы Саклык банкы картасына күчерергә (Әлмәтов Илнур Мәхмүт улы).

3) Акчаны счетка күчерергә мөмкин, реквизитлар түбәндә күрсәтелгән.

ИНН: 1655068682
КПП: 165501001
ОГРН: 1091600003153
ОКПО: 63107012
Расчетный счет: 40703810500027000071
Банк: ПАО «АК БАРС» БАНК
БИК: 049205805
Корр.счет:30101810000000000805
Юридик адрес: 420111, ТР, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт.
Телефон: (843) 225-33-22.
Генераль директор: Мәрданов Булат Раиф улы;
Акчаны күчергәндә «ДЕТЯМ» дип күрсәтергә.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

Казанда физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен ифтар узды

Ел саен Рамазан-шәриф аенда мөфтиятнең "Рамазан – изге гамәлләр ае" марафоны кысаларында "Зәкят" хәйрия фонды белән берлектә төрле социаль чаралар уза.

20 нче апрель көнне Казанда "Туган авылым" милли-туристик комплексында мөфтиятнең социаль үсеш бүлеге тарафыннан тормышка ашырыла торган "Яшь килен", "Затлы мәҗлес" һәм "Исламда беренче адымнар" проектларында катнашучылар физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм аларның әниләре өчен бәйрәм үткәрде. Балалар һәм әниләр Рамазан ае турында тагын да күбрәк белде, үзләре дә Рамазан аена кагылышлы шигырьләр сөйләде, ислам турындагы табышмакларны чиште. Инде күпләргә таныш Тимур Фазлыев матур йомшак тавыш белән Коръән укыды. Аның шигырьләре дә бик тәэсирләндергеч, күңелләргә үтеп керерлек булды.

Аннан соң төрле яшьтәге балалар әлеге чараны оештыруда катнашкан волонтерлар белән, төсле кәгазьләрдән ябыштырып, әниләренә бүләкләр ясады. Ә әниләр хәерле тормыш, Аллаһы белән бәйле элемтәләрне җайга салу, Рамазан ае турында вәгазь тыңлады.

Балалар өчен матур кичә ифтар мәҗлесе белән тәмамланды.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

Казанда Диния нәзарәтенең VIII Корылтае узды

12 нче апрельдә Казанда Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең чираттагы VIII Корылтае узды. Аның эшендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, РФ һәм ТР Президентлары Аппаратлары вәкилләре, министрлар, эре оешма җитәкчеләре, район һәм шәһәрләр башлыклары, республиканың 1500 имамы, массакүләм мәгълүмат чаралары катнашты. Корылтай беренче тапкыр "Казан Экспо"га җыелды.

Корылтайның көн тәртибендәге мәсьәләләр булып Татарстан Мөфтиен һәм Баш казыен, шулай ук Мөфтинең беренче урынбасарын сайлау, нәзарәтнең үткән 4 елда башкарылган эшчәнлегенә йомгак ясау h.б. торды. Шулай ук делегатлар игътибарына нәзарәтнең Казыйлар шурасы һәм Үзәк ревизия комиссиясе хисабы да тәкъдим ителде.

Корылтайның тагын бер мөһим өлеше – нәзарәт казанышлары күргәзмәсе булды. Күргәзмә "ӘМАНӘТ" дип аталган концепция кысаларында төзелде. Корылтайда катнашучыларны шушы сүзне барлыкка китергән зур хәрефләр перспективасы каршы алды. Һәр хәреф мөфтиятнең бер эш юнәлешен чагылдырды:

– Әл-Коръәнне өйрәнү;
– Мәгариф һәм фәнне үстерү;
– Алтын мирасны барлау һәм өйрәнү;
– Нәсыйхәтләр бурычын үтәү;
– Әхлакый кыйммәтләрне ныгыту;
–Туган телне, татар-мөселман гореф-гадәтләрен саклау.

Шулай итеп, мөфтиятнең алдагы 4 елда башкарган эшчәнлеген җыеп, шартлы рәвештә "ӘМАНӘТ" сүзе белән атап булыр иде. Күргәзмә әлеге символик фикерне гәүдәләндерә. Аның эчтәлеге белән теләгән һәркем танышты.

Корылтай эше Коръән аятьләре укып һәм дога кылып башланды. Беренчеләрдән булып делегатлар һәм кунакларны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сәламләде: "Мөфтияткә зур рәхмәтемне әйтәсем килә. Диния нәзарәте тарафыннан нинди зур эшләр башкарылганы күренә: күпме китаплар чыккан, халыкны укыту башкарылган... Алда Татарстан күләмендә генә түгел, бөтен Рәсәй күләмендә 2022 ел бик зур тантаналы чара – Исламны кабул итүнең 1100 еллыгы. Бу эштә безне Президентыбыз В.В.Путин хуплады. Минем тарафтан, хөкүмәт, парламент тарафыннан бөтен планлаштырган эшләребезне бергә-бергә матур итеп эшләрбез. Сезгә һәммәгезгә дә исәнлек, хезмәтегез өчен зур рәхмәт. Шулай матур итеп очрашырга насыйп булсын", – диде.

Соңыннан сүз Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинга бирелде. Ул үз чыгышында үткән 4 ел дәвамында башкарылган эшчәнлеге турында хисап тотты. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның чыгышыннан төп өземтәләр:

Әл-Коръәнне өйрәнү

Коръәнне өйрәнү соңгы 4 елда нәзарәт эшчәнлегендә иң мөһим юнәлеш булып торды. Мөфтият 2017 елда Рәсәй тарихында беренче тапкыр халыкара стандартларга туры килә торган Коръән китабын бастырды. Бу хакта Шәһадәтнамә-не Сүриянең вакфлар министрлыгы бирде.

Шәһадәтнамә бирелгәч, яңа "Казан басмасы" мөселман дөньясында зур кызыксыну уятты: ул Төркиядә, Үзбәкстанда һәм Белоруссиядә бастырылды. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин исә 2019 елда Изге Коръәннең Дубай халыкара премиясе үзәге (DIHQA) тарафыннан Коръән бастыру өстендә эшкә җәлеп ителде. Комиссия эшендә «Казан басмасы»ның өч – 1803, 1914 һәм 2016 еллардагы чыгарылышлары кулланылды.

Нәзарәт Коръәннең асыл мәгънәләрен аңлату

өчен дә Рәсәйдә тулы бер база булдырды. Сүз «Калям Шариф. Переводы смыслов» һәм «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмалары турында бара. Бу ике фундаменталь хезмәт – мөфтиятнең үз тарихында Коръән мәгънәләрен үзе әзерләгән беренче тәрҗемәләре. Тәрҗемәләр китап буларак кына түгел, ә аудиоверсия, Коръән каләме, Коръән лампасы һәм бушлай мобиль кушымталар рәвешендә дә дөньяга чыкты.

Узган дүрт елда нәзарәт республика өчен Коръән буенча кыйммәтле кадрлар да әзерләп өлгерде. 2018 елда Ливандагы Әл-Җинан университетында Рәсәй өчен Коръәннең 10 кыйраәте буенча беренче белгеч – Рушан хәзрәт Йосыпов, белем алып, Татарстанга кайтты. Бүгенге көндә Татарстанда тагын шундый бер белгеч эшли – ул Әхмәт хәзрәт Ибраһимов.

2020 елда, шушы хәзрәтләрне җәлеп итеп, нәзарәт Коръәннең 10 кыйраәте буенча белгечләр әзерләү курсларын да башлап җибәрде. Димәк, тиздән республикада гыйлемле Коръән-хафизлар эшли башлаячак.

Мәгариф һәм фәнне үстерү

Соңгы дүртьеллыкта Татарстанда мөселман мәгарифе күпбаскычлы система буларак формалашып бетте: мәчет каршындагы курслар – мәдрәсәләр – югары уку йортлары – БИА. Хәзер республикада дини гыйлемне Ислам нигезләреннән алып академик дәрәҗәгә кадәр эстәү мөмкинлекләре булдырылды: 2017 елда Болгар ислам академиясе; 2018 елда Әлмәттә – "Нур" татар-мөселман мәктәбе, Балтачта "Ярдәм" мөселман пансионаты; 2019 елда Чистайда – "Камалия" үзәге, Нурлатта Әхмәдзәки Сафиуллин исемендәге тәгълим үзәге, Яшел Үзәндә мәдрәсә бинасы; 2020 елда Алабугада "Ихсан" мәктәбе; 2021 елда беренче татар онлайн-мәдрәсәсе ачылды.

Бүгенге көндә Татарстанда мәчет каршындагы курсларда ислам нигезләре буенча белем алучылар саны 15 меңгә җитте.

Моннан тыш, Диния нәзарәте фәнни үзәк дәрәҗәсендә дә үз эшен дәвам итте. Бу аеруча фәтвалар чыгаруда, исламның классик ядкәрләрен тәрҗемә итүдә, фундаменталь хезмәтләр әзерләп бастыруда, республикада Хәнәфи мәзһәбе һәм татар-мөселман традицияләрен саклау өчен теоретик механизмнар эшләүдә чагылды. 2017-2021 елларда рус телендә – 173, татар телендә – 161 фәтва чыгарылды. "ТР МДН имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә" эшләнде; Рәсәйдә беренче тапкыр Әбү Мансур Әл-Матуридиның "Китаб әт-тәүхид" китабы һәм легендар "Алты Бармак" китабы русчага тәрҗемә ителеп бастырылды, Ш.Мәрҗанинең алты томлык әсәрләре җыентыгы h.б. чыкты; 9 дәреслек әзерләнде.

Татар дини мирасны саклау һәм өйрәнү

Бу эш түбәндәге юнәлешләрдә бара:

Иске татар дини китапларны эзләү, цифрлаштырып мәңгеләштерү һәм дөньяга ачу – Darul-Kutub.com онлайн-китапханәсе фонды соңгы 4 ел эчендә 1918 елга кадәр чыккан 1200 китап белән тулыландырылды. Бушлай китапханәдә барлыгы 1300 иске китап бар. Аларны бушлай укырга һәм йөкләп күчереп алырга мөмкин.

Татар дин галимнәренең фәнни хезмәтләрен бастыру – хисап чорында "Хозур" нәшрияты халкыбызның күренекле хәзрәтләре иҗат иткән 44 исемдәге китап бастырды. Аларның гомуми тиражы 38 350 данәгә җитә.

Татар дини мирасы буенча гарәп телендә фәнни эшләр язу – Нәзарәт хәзрәтләрне Болгар ислам академиясенә укырга шушы максатны күз алдында тотып җибәрә. Татар дини мирасы буенча БИАда 4 докторлык һәм 2 магистрлык диссертацияләре якланды.

Татар дин галимнәренең исемнәрен попу-

лярлаштыру – 30лап фәнни-гамәли конференция үткәрелде, 2 документаль фильм төшерелде, галимнәр рухына ел саен җәмәгать белән дога кылынды.

2017 елда Казан Кремлендә нәзарәт тырышлыгы белән татар ханнарының җәсәдләре җир куенына иңдерелде.

Нәсыйхәтләү һәм дәгъват эшчәнлеге

Хисап чорында дәгъват эше нәзарәттә берничә юнәлештә алып барылды:

Китаплар нәшер ителде – 2017 елдан “Хозур” нәшрият йортында 163 исемдәге китап бастырылды. Аларның гомуми тиражы 361 285 данә тәшкил итә. Китапларны huzurshop.ru сайтында читтән торып сатып алырга мөмкин.

Массакүләм мәгълүмат чараларында дәгъват алып барылды – 2017 елдан башлап “Хозур” нәшрият йорты Россиядә иң эре мөселман медиахолдингларның берсенә әйләнде: 2018 елда “Хозур ТВ” мөселман телеканалы эшли башлады (ул бүгенге көндә Интернет челтәрендә һәм илнең 9 төбәгендә күрсәтә, «Islam-today.ru» – Рәсәй һәм БДБ илләрендәге иң зур мөселман интернет-порталы, аны аена 2,5 млн кеше кереп укый, “Азан” мөселман радиосы – аны тәүлегенә 10 мең кеше тыңлый, “Шура” журналы, «Умма», «Дин вә мәгыйшәт» газеталарының гомуми тиражы 416 000 данә тәшкил итә).

Интернет челтәрендә нәсыйхәт бирелде – социаль челтәрләрдә – 41 аккаунт, 10 түләүсез мобиль кушымта эшләнде.

2017 елдан бирле Татарстанда 78 мәчет ачылды.

2019 елда “Даруль ифта” беренче бушлай федераль номерлы мөселман call-үзәге эшли башлады.

2018 елдан бирле “Ислам. Беренче адымнар” проекты кысаларында 637 кеше намаз укырга өйрәнде.

Динара татулыкны саклау: 2017 елда Диния нәзарәтенә БМО каршында Консультатив статус бирелде; Нәзарәт чит илләрдә, шул исәптән, Аурупада иминлек һәм хезмәттәшлек буенча Оешма (ОБСЕ) утырышларында, тату динара мөнәсәбәтләрне урнаштыру буенча эксперт буларак җәлеп ителә; terrora-net.ru адресы буенча урнашкан «Ислам против террора» порталы эшләнде; «Ислам без стереотипов», «Сирия. Билет в один конец», «Путь в никуда» дигән документаль фильмнар әзерләнде; төрле дин вәкилләре арасында спорт ярышлары уздырылды.

Әхлакый кыйммәтләрне ныгыту

Әхлакый кыйммәтләрне ныгыту эше аеруча яшьләр арасында барды, хәйриячелектә чагылды һәм төрмәләрдә башкарылды.

2017 елдан башлап яшьләр өчен барлыгы 50 проект тормышка ашырылды: 1000нән артык кешедән торган волонтерлар хәрәкәте оешты; мөселман яшьләренең VIII Кышкы һәм Җәйге форумнары; ислам турында популяр темалар буенча ачык Лекторийлар һәм бәхәс клублары эшләде; сәламәт яшәү рәвеше тәрбиләнде – Мәрҗани исемендәге джиу-джитсу буенча ярышлар, Диния нәзарәте Кубогына татарча көрәш һәм кул көрәше буенча республика ярышлары оештырылды.

Хәйрия эшчәнлеге: “Зәкят” хәйрия фонды 300гә якын авыруның дәвалану курслары өчен түләде; 2017 елда авыру балалар һәм аларның әти-әниләре өчен “Хәят” социальләшү үзәге ачылды; 2019 елда Казанда инвалид балалар, яшүсмерләр, яшьләрне кыска вакытка калдырып тору Үзәге ачылды; 2017-2020 еллар аралыгында Республикакүләм ифтарлар оештырылды; 2017 елдан башлап сукбайлар өчен даими хәйрия ашлары уздырыла (көн саен 500 мохтаҗ кайнар аш белән тәэмин ителә); 4 ел эчендә, шул исәптән, Рамазан айларында һәм Корбан гаетләрендә, 10,6 мең мохтаҗ гаилә ризык җыелмалары һәм ит белән тәэмин ителде; Татарстанда гошер җыю гадәте кайтарылды һәм 4 ел эчендә мохтаҗларга 2,8 мең тонна ризык таратылды.

Җәзага тартылган мөселманнарны тәрбиләү: Татарстанның барлык колониләрендә мәчетләр яки намаз уку бүлмәләре булдырылды; аларда махсус әзерлекле 10 имам эшли һәм «Хозур» нәшрияты чыгарган дини әдәбият белән тәэмин ителә; тоткыннарга вәгазләр укыла, дин белән бәйле сораулларга җавап бирелә, дини бәйрәмнәр һәм бәйгеләр оештырыла.

Туган телне һәм татар-мөселман гореф-гадәтләрен саклау

Туган тел – Аллаһыдан әманәт. Шушы нәсыйхәт нәзарәтнең соңгы 4 ел дәвамындагы эшчәнлегендә кызыл җеп булып сузылды:

2019 елда “ТР МДН имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә” эшләнде. Ул Татарстанда татар-мөселман гореф-гадәтләрен саклау механизмы булып тора.

Махсус мәктәпләр ачылды: 2019 елда – Әлмәттә “Нур” татар-мөселман мәктәбе; 2019 елда – Балтач районында малайлар өчен “Ярдәм” мөселман пансионаты; 2020 елда – Алабугада “Ихсан” мәктәбе; 2021 елда беренче татар онлайн-мәдрәсәсе эшли башлады; 100 мәчеттә татар теле курслары оештырылды; “Татар теле. Башлап өйрәнүчеләр өчен” дәреслеге әзерләнде.

Мәчетләрдә татар телле мохит тудырылды: вәгазләр татар телендә сөйләнә; балалар һәм яшьләр өчен татар телендә эш алып бара торган кышкы һәм җәйге каникуллар оештырыла; халыкка дини консультацияләр татар телендә бирелә; барлык чаралар татар телендә уздырыла; эш кәгазьләре һәм үзара эшлекле мөнәсәбәтләр татар телендә алып барыла.

Татарлар арасында милли-дини үзаң тәрбиләү: Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин “Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә” басмасында милләттәшләргә махсус мөрәҗәгать белән чыкты; Рәсәй төбәкләрендә татарлар белән очрашулар оешытырылды; “Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә” белән “китаплы рейслар” милләттәшләргә тарату өчен 15 мөфтият һәм милли оешмага җибәрелде.

Үзенең чыгышында Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт шушы эшләрне башкаруда ярдәм күрсәткәннәре өчен республика җитәкчелеге, имамнар, район һәм шәһәр башлыкларына, иганәчеләргә, министрлыкларга, ведомстволарга, дәүләт оешмаларына рәхмәтен белдерде.

Корылтайда катнашучыларны сәламләп, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов шулай ук нәзарәткә рәхмәт сүзләрен, теләкләрен җиткерде:

– Мөхтәрәм җәмәгать, безнең милләтебез өчен динебездән башка рухи кыйблабыз юк. Ул – безнең иң зур кыйммәтебез дә, рухи кыйблабыз да. Мин бик сөендем: мөфтиебез үз чыгышында мөкатдәс әманәтләр исемлегендә безнең туган телебез язмышын да атады. Ә менә инде Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясенә җитәкче булып килгәндә, миңа һәрдаим эзләнергә туры килә, чөнки элекке хезмәт-вазифам аның белән бәйле түгел иде. Менә бу яңа вазифалар буенча халкыбыз, милләттәшләребезнең күңеленә, йөрәгенә ничек итеп керергә соң, ничек итеп телнең байлыгын, әдәби матурлыгын, аңа булган рухи ихтыяҗны ничек сөндерергә соң дигән сорауга җавап эзләп, мин, иң беренче чиратта, мөфтиебез янына килдем. Безнең бик матур берничә очрашу үтте, киңәшләштек. Мин, чыннан да, үзебезнең мөхтәсибәтләребезне, мәчетләребезне һәм анда йөрүче йөзләгән мең милләттәшебезне иң зур аудитория дип саныйм. Халык белән аралашу өчен моннан да зуррак аудитория юк. Чөнки бирегә килгән кеше үзенең аңын, күңелен чистартырга, Аллаһы Тәгалә белән сөйләшергә килә. Үзенең кыйбласын эзләп килгән кешеләр бит инде алар. Бу очракта безгә урыннарда эшли торган имамнарыбызның халкыбызга үтемле итеп телебез язмышы, аның киләчәге турында җиткерә алулары бик кирәк. Беренче чиратта, мөхтәсибәт җитәкчесеме, мәхәллә җитәкчесе буларак имаммы – аларның тел осталыгы бик кирәк. Туган, татар телебезнең матурлыгын да без сезнең белән бергә күтәрә алабыз, сөйләшә белмичә, татар теленең матурлыгын да төшерә алабыз. Менә шуңа күрә дә беренче үтенечләремнең берсе мөфтигә шул булды: без имамнарыбызны тел, вәгазь осталыгына өйрәтик әле, тыңлаучының да күңеленә үтеп керерлек матур вәгазь осталыгына өйрәнсеннәр әле дигән теләк белдергән идем. Бу очракта нәзарәт безне ишетте. Һәм бу эш алып барыла. Киләчәктә без мәхәлләләргә йөрүче милләттәшләребезгә телебезнең матурлыгын, тирәнлеген, күбрәк итеп, үтемлерәк итеп сөндерә алырбыз дип уйлыйм. Диния нәзарәте киләчәктә дә телебез язмышына олы хезмәт итә ала. Мөфтинең чыгышында күрдек ки, халык белән эшләү өчен бихисап зур, заманча технологияләр белән җиһазландырылган инфраструктура булдырылган. Әлбәттә, бу халык белән, милләттәшләребез белән элемтә дигән сүз. Мин бик ышанам, киләчәктә без сезнең белән телебезнең матурлыгын, нәфислеген, әдәбилеген күрсәтә алырбыз.

Көн тәртибендәге ТР Мөфтиен сайлау турындагы мәсьәлә буенча ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең 2021 елның 27 нче гыйнварында узган Пленумы карары белән кандидат булып Камил хәзрәт Сәмигуллин күрсәтелде һәм ул делегатлар тарафыннан бертавыштан сайланды.

ТР Баш казыена кандидат итеп Җәлил хәзрәт Фазлыев күрсәтелде һәм ул шулай ук делегатлар тарафыннан бертавыштан сайланды.

Татарстан Мөфтиенең беренче урынбасары итеп “Кол Шәриф” мәчете имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов сайланды.

Съезд җәмәгать белән намаз укып тәмамланды. 1500 имам Камил хәзрәткә ияреп өйлә намазын башкарды.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

Рамазанда Коръән укуның фазыйләтләре



Бөтен дөньяларны юктан бар кылып, безгә җан иңдереп һәм күп төрле нигъмәтләрен бирүче Аллаһы Тәгаләгә шөкерләр һәм дан-мактаулар булса иде. Пәйгамбәрләребезнең соңгысы булган Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

«Рамазан ае – аңарда кешеләр өчен һидаять, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, хакны ялганнан аерган Коръән иңдерелгән [ай]...»

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Рамазан ае – ул ураза тоту, дога кылу, күп гыйбадәтләр ае гына түгел, бу ай – Коръән ае да. Бу айда бөек, мөбарәк Кадер кичендә Коръән иңде. Коръәннең тәфсирен иң яхшы белүче сәхабәләрнең берсе Габдулла бине Габбас әйтүенчә, Коръән Кадер кичендә Ләүхүл-Мәхфүздән беренче күккә иңдерелде һәм шуннан Җәбраил галәйһиссәлам Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә 23 ел эчендә өлешләп-өлешләп китереп торды. Башка китаплардан аермалы буларак, Аллаһы Коръәнне Пәйгамбәребезгә, Мусага Синай тавында Тәүратны биргән кебек, әзер китап буларак тапшырмады, ә өлешләп бирде. Коръәннең өлешләп иңүендә зур хикмәтләр бар. Аллаһы Тәгалә аларны Коръәндә искә ала:

1. Аллаһы Пәйгамбәребезне ныгытып торды, аны юатты һәм көрәшкә рухландырды.

«...Аның белән синең күңелеңне куәтләндерик [тә аны җиңел генә хәтереңдә калдыр] дип [аны егерме өч ел кебек дәвамлы вакыт эчендә өлешләп иңдердек]. Һәм Без аны тәфсилләп бәян иттек».

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:32

Мөшрикләр Пәйгамбәребезне төрле әшәке сүзләр белән рәнҗәтеләр, аңа сихерче, ялганчы дип яла яктылар, төрле каршылыклар күрсәттеләр. Болар барысы да аның күңелен төшерә, аны борчый иде. Бу хакта Раббыбыз болай дип әйткән:

«Шуңа күрә аларның [Аллаһы Тәгалә хакындагы инкяр һәм ширек тулы, синең хакта исә нәфрәтле һәм мыскыллы] сүзләре сине борчымасын. Без алар яшергән нәрсәне дә, күрсәткән нәрсәне дә беләбез».

«Йәсин», 36:76

Әмма Аллаһы аңа Җәбраил галәйһиссәламне җибәреп аятьләр иңдереп торгач: «Аллаһы минем белән бит, мин ялгыз түгел», – дип рухланып, үзенә көч ала торган булды. Әгәр дә аңа вәхи килү бераз туктап торса, ул моның өчен бик кайгырды һәм Җәбраил галәйһиссәламне сагынып көтә торган иде.

2. Мөэминнәрнең ихласлыкларын һәм аларны диндә ныгыту өчен, Коръәннең өлешләп иңүе сәхабәләрне әкренләп тәрбияләде, камилләштерде. Алар үзләре дә Пәйгамбәребезнең аларга Аллаһының яңа аятьләрен укуын көтәләр иде.

3. Коръән аятьләре сәхабәләрнең күңелләрендә нык уелып калсын, алар аятьләрнең иңү сәбәпләрен белеп, яхшы аңласыннар һәм аларга аятьләрне ятларга җиңелрәк булсын өчен.

4. Кяферләрнең, монафикъларның һәм яһүдиләрнең мәкерләрен фаш итү өчен.

Шуңа күрә бу аларга бер дә ошамый иде, аларның планнары җимерелә иде.

«Кяфер булган кешеләр [синең пәйгамбәрлегеңә каршы төшәр өчен]: «[Бүтән пәйгамбәрләргә иңдерелгән китаплар кебек] Коръән [дә] аңа нишләп тулысынча берьюлы иңдерелмәде?» – диде».

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:32

5. Бирелгән сорауларга, килеп туган мәсьәләгә җавап бирү өчен, нинди генә хәл, вакыйга булмасын, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә шунда ук бу хакта аятьләр иңә иде.

6. Коръәннең Аллаһыдан килгәнен исбатлар өчен. Кяферләр: «Коръәнне Мөхәммәд үзе язды, яки аңа кемдер әйтеп торды, яки ул элекке китаплардан күчереп алды, яки ул эпилепсия белән чирләп, өянәк вакытында аңа төрле сүзләр ишетелгән. Ул шуларны Аллаһыдан дип аңлаган», – дип һәм башка төрле шуңа охшаш сүзләр сөйләделәр һәм сөйлиләр. Мөшрикләр һәм яһүдиләр Пәйгамбәребезне тикшереп, төрле сораулар бирәләр иде. Шуннан соң бик тиздән аларга җавап та килә торган булды. Бу аларны аптырашта калдыра иде.

7. «Алар [синең хаклыгыңны белгәннәре өчен, асылда] сине ялганчыга санамыйлар, ләкин залимнәр Аллаһының аятьләрен [хак булганын белә торып] инкяр итәләр».

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:33

Коръән – Аллаһының Китабы, Аның Сүзләре. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән соң бүтән пәйгамбәр булмас һәм Китап та иңмәс. Аллаһы Коръән белән Үзенең динен төгәлләде, камил кылды. Коръәндә:

«Бүген сезнең өчен динегезне камил иттем, [Мәккәне алуны насыйп итү белән динегезне бөтен, ялган диннәрдән өстен кылып] сезгә нигъмәтемне тәмамладым һәм сезнең өчен, дин буларак, Исламнан канәгатьмен», – дип әйтелгән.

«Әл-Маидә / Табын», 5:3

Коръәннең үзенчәлеге тагын шунда ки: Аллаһы башка китапларны һәм расүлләрне билгеле бер халыкка гына җибәрде. Мәсәлән, Тәүрат һәм Инҗил китаплары бары тик яһүдиләргә генә бирелгән иде. Ә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бөтен халыкларга да җибәрелде һәм Коръән дә бөтен халыклар өчен дә иңдерелде. Аллаһы Коръәндә тормышның максаты һәм мәгънәсен аңлата, кеше үзен борчыган сорауларына җавапны шуннан таба. Исламга килгән күп кеше, үзләренең исламга килү тарихларын сөйләгәндә, үзләренең күп китаплар укулары, хаклыкны күп эзләүләре хакында сөйли. Ә инде ахырдан Коръәнне алып укыгач, үзләренең тәэсирләнгәннәрен, борчыган сорауларына җавап табуларын һәм, ниһаять, тынычланулары хакында сөйли.

Коръән уку өстенлеге

Галимнәр Коръән уку белемен иң хөрмәтле белемнәрдән дип әйтте. Аллаһы Үзе безгә шуны әмер итә:

«...Коръәнне тәртил белән [әкрен-әкрен, ачык итеп] укы».

«Әл-Мүзәммил / Чорналган», 73:4

Коръән укуның өстенлеге хакында Аллаһы Коръәннең үзендә дә искә ала, мәсәлән:

«Кешеләр Без биргән [Тәүрат һәм Инҗил дигән] китапны хак уку белән укыйлар [сүзләрен үзгәртмиләр, мәгънәсенә төшенәләр]. Алар аңа ышаналар. Кем дә кем [Китапны үзгәртеп яки хөкемнәрен кире кагып] аны инкяр итсә, шулар – [үзләрен матди һәм рухи зараргa дучар итеп] югалтучылар».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:121

Хак уку белән уку, Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе һәм Ибне Габбас радыяллаһу ганһе аңлатуынча, ул укыган белән гамәл кылу, укыган белән яшәү, андагы хәләлне хәләл итеп һәм харамны харам итеп алу буладыр. Менә болар чын мөэминнәр булырлар. Ә Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе фикеренчә, хак уку – ул Аллаһының рәхмәте хакында аятьләр укылганда, Аның рәхмәтен сорау, газап хакында аятьләр укылганда, Аллаһыга сыенудыр.

Коръәнне уку өстенлекләре, әлбәттә, Сөннәттә дә килә:

1. Коръәннең һәр хәрефе өчен әҗер булыр.

Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Кем Аллаһының китабыннан бер хәреф укыса, аңа бер изгелек язылыр. Ә бу изгелек тагы ун тапкырга арттырылыр. Мин «Әлиф Ләм Мим» бер хәреф дип әйтмим, әмма «Әлиф» – ул бер хәреф, «Ләм» – ул бер хәреф, «Мим» – ул бер хәреф (имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан).

2. Коръән укучы янында фәрештәләр булыр.

Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Коръәнне оста укучы белән илче фәрештәләр булыр. Ә кем инде Коръәнне тотлыгып, авырлык белән укыса, аңа ике әҗер булыр» (имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

3. Коръән укучының күңеленә тынычлык иңәр һәм рәхмәт аны чолгап алыр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр бер төркем кеше Аллаһының йортына җыелып, Аллаһының Китабын укыса һәм аны өйрәнсә, аларга тынычлык иңәр, һәм рәхмәт аларны чолгап алыр, фәрештәләр аларны каплар һәм Аллаһы аларны Үзе янындагыларга мактап искә алыр», – дип әйткән (имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

4. Коръән укучысына шәфәгатьче булыр.

Пәйгамбәребез: «Коръәнне укыгыз, чөнки ул укучыларына Кыямәт көнендә шәфәгатьче булыр», – дигән (имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Коръән – ул һидаятьне, туры юлны күрсәтүче дә, нур да, тәннәргә һәм җаннарга шифа да. Ул берәүләрне югары күтәрә, ә берәүләрне түбән итә. Ул – Аллаһының рәхмәте, ул тиңе булмаган могҗизадыр.

Әмма без бу Китапның кадерен генә аңлап бетермибез, аңа карата без гафилбез. Коръәндә:

«Алар Коръән турында һич уйламыйлармы [моның кадәр нәсыйхәтләргә карамастан, шундый хәлгә төшәләр]? Әллә [каты һәм надан] йөрәкләрендә йозаклар бармы?» – дип әйтелгән.

«Мөхәммәд», 47:24

Сәхабәләрнең һәм табигыйннәрнең Коръән укуларына игътибар итсәк, әлбәттә, без алар кебек булдыра алмабыз. Әмма көнгә, иң кимендә, бер-ике бит укуны барыбыз да булдырабыз. Бу вакытта без Коръәнгә карата гафилләрдән һәм Коръәнне калдыручылардан булмабыз. Иң мөһиме: Коръән көн саен безнең кулда булсын, бигрәк тә бу мөбарәк Рамазан аенда. Гафил булмыйк, Коръәнне укыйк һәм укырга өйрәник.

■ **Марат хәзрәт СӘЙФЕТДИНОВ,**
Балтач Үзәк мәчетенең
икенче имамы

Рамазан – кадерле кунак

Туган көн, яңа ел, әниләр көне кебек бәйрәмнәрне алдан ук көтеп алабыз. Һәм шундый ук зарыгу белән, Рамазан аен да көтәргә тиешбез.

Вакыт беркайчан да туктап тормый, ничек кенә Рамазан ае озаграк торсын дип теләсәк тә, ул барыбер узачак. Шуңа да, мөмкинлек булганда, Рамазан аен кадерлик. Әгәр дә безгә берәр кунак килергә җыенса, без өйләребезне җыештырабыз, кунакларны матур итеп каршы алабыз, алар безнең өйдә булганда үзебезне дә гадәттәгечә түгел, ә бүтәнчәрәк тотабыз, ә киткәндә, моңсуланып озатып калабыз. Шулай ук Рамазан ае да бик кадерле кунак.

Безнең якларда бу айны “ураза ае” дип тә йөртәләр. Әлбәттә, моның да үз нигезе бар, чөнки Рамазан ае дигәч, нәкъ менә ураза күз алдына килә. Әмма ураза тоту бу айда гына булмаганлыктан, Рамазанны аның белән генә чикләргә ярамый. Дөреслектә, бу бик фазыйләтле, бүләкләргә бай ай. Аллаһы Тәгалә бу айны калган айлардан аерып куйды. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу ай турында бик күп хәдисләр әйтеп калдырды.

Нәрсә соң ул ураза?

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: “Мөэмин ураза тотып та, ачлыктан башка бер нәрсәгә дә ирешмәскә мөмкин”, – дип әйтә. Рамазан аенда безнең күзебез дә, колагыбыз да, телебез дә, йөрәгебез дә ураза тота. Ураза тотучының йөрәге тәкәбберлектән, көнчелектән, икейөзлелектән, ачудан пакь булыр. Тик иң мөһиме, ураза тоту – Аллаһыга гыйбадәт кылу икәнен онытмасак иде.

Рамазан безне шәйтаннан саклый, изге гамәлләр кылып калыйк

Рамазан аеның бер фазыйләте булып, шәйтаннарның ай буе богауда булулары тора. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан ае килү белән җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла, ә шәйтаннар богауланып куела», – дип әйтә. Бу, вәсвәсә кыла торган шәйтаннарның булмавы, шуңа да бик күп итеп изге гамәлләр кылып калу мөмкинлеге була, дигәнне аңлата. Ә кем дә кем үзен изге гамәлләр кылырга ияләштерә, ул Рамазаннан соң да шулай ук дәвам итәчәк. Гомумән, кешенең уразалы булган көне уразасыз көненнән аерылып торырга тиеш. Ә шәйтаннарның богауда булуы моңа ярдәм итә. Шушы ук хәдистә җәннәт ишекләренең ачылуы һәм җәһәннәм ишекләренең ябылуы хакында әйтелә.

Кадер кичәсе

Рамазан аен ел буе сагынып көтсәң дә, изге көннәр сизелми дә үтә. Раббысына тугры булган бәндә көн саен кадерле вакытларын изге гамәл кылуга, Коръән укуга багышлый. Тоткан ураза калебләрне йомшарта, үтәгән намазлар кешене сабыр, әхлаклы итә, укыган аятьләр гафиллектән уята. Тән итагать кыла, тел зикер итә, җан уйлана, гыйбрәт ала.

Кунакның китәр вакытлары җиткәч, кадере арта. Шулай ук Рамазанның ахыргы 10 көне дә безнең өчен аеруча гыйззәтле. Ул көннәрдә иман әһеленең изгелекләре өстәлә, «Рәхмәтенә ирешермен, гөнаһымнан пакьләнермен, уттан котылырмын», – дигән өметләр арта. Гайшә радыяллаһу ганһә: «Аллаһы Расүле Рамазанның ахыргы ун көнендә башка көннәргә караганда ныграк иҗтиһад, тырышлык күрсәтте», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ул көннәр турында: «Рамазанның ахыргы 10 көне – ул җәһәннәм газабыннан котылу көннәре», – дигән.

Рамазан аеның иң мәртәбәле көннәрендә Коръән индерелгән Кадер кичәсе яшеренеп тора. Бу кичәдә әҗер-саваплар бергә – мең бәрабәрендә языла. Бу кичәнең тулы кадерен һәм кыйммәтен бары тик ураза тотып, үз нәфесләрен тәрбияли алган кешеләр генә, нечкә күңелләр, ихлас коллар гына тоя аладыр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

“Һичшиксез, Без аны [мәңгелек могҗиза булган Коръәни Кәримне] Кадер кичәсендә [Ләүхүл-Мәхфүздән тулы килеш беренче кат күккә] индердек. Кадер кичәсенең нинди икәнен син каян белә аласың? Кадер кичәсе [Кадер кичәсе булмаган] мең айдан да хәерлерәк. [Шул сәбәпле, аңарда кылынган изге гамәл сиксән өч ел да дүрт ай буена бертуктаусыз кылынган гамәлгә тиң генә түгел, аннан да фазыйләтлерәк]. Ул кичәдә, Раббыларының рөхсәте белән, фәрештәләр һәм Рух [дип тә аталган Җәбраил [галәйһиссәлам] һәртөрле эш өчен иңәләр. Таң атканчы [фәрештәләр очраткан һәр иманлы ир һәм хатынга сәлам биргәннәре өчен] ул [кичә] иминлек [булыр]».

«Әл-Кадр / Кадер киче», 97:1-5

Ни өчен соң ул төн «Кадер киче» дип аталды?

Кадер – ул «кодрәт», бу төн Аллаһы каршында иң кодрәтле һәм иң хөрмәтле төндер. Аның икенче мәгънәсе – «тәкъдир», бу төндә ел әйләнәсенең язмышы тәкъдир кылына. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

«Анда һәр хикмәтле эш аерыла».

«Әд-Духан / Төтен», 44:4

Бу кичәдә фәрештәләр адәм баласының берьеллык тәкъдирен алып киләләр. Соңрак Кадер төнен Коръән иңү белән үзенчәлекле иткән Аллаһы, ул төннең тагын бер өстенлеген бәян итеп: «Кадер төне мең айдан хәерлерәк», – дип әйтә. Ул төнне догада, гыйбадәттә, зикердә, намазда үткәргән бәндә мең ай гыйбадәт кылудан да зуррак әҗер алачактыр.

Мең ай – ул 83 ел һәм 4 ай була

Ул төндә җир йөзенә Аллаһы кешеләргә тәкъдир кылган һәрбер яхшы вә яман эш белән Җәбраил галәйһиссәлам һәм башка фәрештәләр төшәләр. «Ул таң беленгәнче иминлектер», ягъни Кадер төнендә җир өстенә төшкән фәрештәләр бәрәкәт, тынычлык һәм хәерлелек белән төшәләр. Бигрәк тә ул фәрештәләр Коръән укучылар, Аллаһыны зикер итүчеләр һәм гыйлем эстәүчеләр белән бергә булалар. Шәйтан да ул төнне үзенең мәкерлекләрен кыла алмый.

Кадер төне кайчан була? Мөселманнар өчен айлар арасында Рамазан ае, көннәр арасында җомга көне, кичләр арасында Кадер кичәсе иң мөбарәк санала. Кадер кичәсе Рамазан-шәриф аенда булган бер кичәдер. Шул ук вакытта Рамазанның кайсы кичәсендә булганы төгәл һәм ачык рәвештә билгеләнмәгән. Бу мәсьәләдә галимнәр төрле фикердә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кадер төне – Рамазанның ахыргы ун төнендә. Кем аларны уяу үткәрсә, Аллаһы аның кылган һәм кылачак гөнаһларын кичерер. Бу – так санлы төндә: 23, 25, 27, 29ында», – дип әйткән.

Кадер төненең үз галәмәтләре бар. Галимнәр билгеләп үткәнчә, Кадер кичәсен кайбер галәмәтләрдән, шул кичкә хас булган аерым билгеләрдән тәгаенләргә мөмкин: бу кичә нурлы, тыныч һәм матур булыр; бик салкын да, бик эссе дә булмас; ул кичтә болытлар йөрмәс һәм җил исмәс, һавадан йолдызлар атылмас, яңгыр яумас, барча җиһанда тылсымлы тынлык урнашыр. Шул төн арты кояш, нурсыз пакь тулы ай кебек чыгар.

Кадер кичәсе гыйбадәте: бу кичә Аллаһының рәхмәте бик мул булган бер кичәдер. Көндез ихтыяҗы булганнарга мөмкин кадәр ярдәм итәргә, авыз ачканда фәкыйрьләрне ашатып-эчертергә, кичен Коръән укып, гыйбадәт кылып, үткәрергә кирәк. Гыйбадәттә каза намазын кылу, Коръәни Кәримнән сүрәләр, догалар уку, тәүбә итү, садака бирү, мөселманнарны сөендерү һәм башка саваплар казану – болар барысы да бу кичәгә хөрмәт күрсәтүнең ишарәседер. Хөрмәт күрсәтү гөнаһлы эшләрне эшләмәү белән дә хасил булыр.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәү, Аллаһы Тәгаләгә инанып һәм савабына өметләнеп, Кадер кичәсен гыйбадәт кылып уздырса, элек кылган гөнаһлары гафу ителәчәк», – дип әйткән.

Шулай ук кайбер риваятьләрдә Кадер кичәсендә иң азы – ике рәкәгать, уртача – йөз рәкәгать, ә иң күбе – бер мең рәкәгатьле намаз укылуы хәбәр ителә.

Бу намазны нәкъ шул рәвешле уку мәҗбүри түгел, әмма аны болай уку мәслихәт булуын хәбәр итә торган риваятләр бар. Төп максат булып, мөселманнарның бу төнне гыйбадәт һәм зикердә үткәрүе тора.

Кадер кичәсендә укыла торган дога. «Хәзрәти Гайшә радыяллаһу ганһә: «Йә, Расүлуллаһ, Кадер кичәсенең кайсы кичә икәнен белсәк, ул кичтә ни дип әйтергә кирәк?» – дип сораганына, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу доганы укырга кушкан:

«Аллаһуммә иннәкә гафүвүн кәриимүн, түхиббүл-гафүә, фәгъфү ганнии».

Мәгънәсе: *«Йә, Аллаһым, һичшиксез, Син Гафу кылучы, Син юмартлык Иясе, Син гафу итәргә яратасың, мине гафу ит».*

Аллаһы Тәгалә ниятләребезне саф, чиста кылса иде. Кыямәт көнендә тоткан уразаларыбыз, укыган намазларыбыз өчен шатланышып, Әр-Раййән ишекләреннән Аллаһы Тәгалә вәгъдә иткән җәннәтләргә керү насыйп булса иде.

■ **“Кунак килә, каршы ал! Рамазан аена әзерлек”** китабыннан



■ **dumrt.ru** сайтыннан



Хакыйкатьне сөйли торган Китап

Коръәни Кәримне һәркем укый ала. Аны укырга да, аңларга да, ятларга да җәйлы. Ул үзе дә безгә барысын да аңлатырга теләгәнен әйтә. Аның төп үзенчәлеге – укыганда һәм ятлаганда уңайлы булуы. Җир йөзендә мондый сыйфатларга ия булган башка китап юк.

Без хакыйкатьне тагын да яхшырак аңласын өчен, Коръәндә хикәяләр бәян ителгән. Чыннан, болай уку китапны тагын да аңлаешлырак итә.

Шулай да кайбер аятьләрне аңлап бетермәскә мөмкинбез. Мондый вакытларда тәфсирләргә мөрәҗәгать итәбез. “Тәфсир” – Коръәннең мәгънәсен җентекләп аңлаткан китап ул.

Кешеләрне яктылыкка чыгара торган Китап

Коръәни Кәрим кешеләрне иң дөрес һәм иң яхшы булганнарга чакыра. Аның чакыруын ишетеп, ул әйткәннәргә “колак салган” кеше адашкан юлдан яктылыкка, тугры юлга, хакыйкатькә чыга. Аның ярдәме белән кеше үзен начар сыйфатларыннан азат итеп, нәфесенең колы булудан туктый һәм үзен күпкә бәхетле итеп хис итә башлый.

Коръәни Кәримне кабул иткән, аның буенча яши башлаган кеше гаиләсе, күршеләре, туганнары, гомумән һәркем белән яхшы мөгамәләдә була. Коръәннән тайпылмаган кеше хәләл юл белән мал туплый, ялганнан, харамнан ераклаша. Күңелендә икейөзлелек булса – ихласлыкка, үз-үзен ярату, мактану булса – тыйнаклыкка алышына.

Коръән хатын-кызның дәрәҗәсен күтәргән, аны бөекләгән, һәркемнән дә аны хөрмәт итүләрен таләп иткән Китап.

Коръән авыруларга, мохтаҗларга, кыерсытылганнарга мәрхәмәтле, ярдәмчел булырга өйрәткән Китап.

Коръән кешеләр өчен нур булып балкыды. Ул йөрәкләрдәге караңгылыкны яктылык, чисталык белән тутырды. Калебләр тынычлык, өмет, бәхет-сәгадәт белән тулды.

Коръәни Кәрим кешеләрне үзара бүлешергә, начардан сакланырга, яратырга, гафу итәргә, ярдәм кулы сузарга өйрәтте. Димәк, Коръән – ул безнең укытучыбыз, нәсыйхәтчебез. Безнең бурыч бу нәсыйхәтләрне, дәресләрне кабул итү, үтәп яшәү. Хәтта боларны кире кагырга теләсәк тә, бик нык ялгышкан булырбыз, чөнки безнең бәхетле булу-булмавыбыз Коръән буенча яшәү-яшәмәүгә бәйле.

■ Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде

ТР МДННең “Хозур” нәшрият йорты «Клад для маленьких мусульман» (“Нәни мөселманнар өчен хәзинә”) исемле китап нәшер итте

Олылар дөньясы зур һәм катлаулы итеп корылган. Кечкенә мөселманга аны ничек аңларга соң? Без нәрсәгә ышанырга тиеш? Кем Ул – безнең барлыкка Китерүчебез? Кемнәр ул фәрештәләр? Ә пәйгамбәрләр турында нәрсә беләбез? Бу дөнья белән нинди кануннар идарә итә? Безгә нинди вазифалар йөкләнгән? Һәр мөселманның тормышында иң мөһиме булып нәрсә тора?

Гакыйдәнең барлык бу җитди сорауларына җаваплар Мәликә Өмме Яхъяның ТР МДНенең “Хозур” нәшрият йорты бастырган «Клад для маленьких мусульман» (“Нәни мөселманнар өчен хәзинә”) исемле китабында бирелгән. Биредә гакыйдә фәненең иң авыр төшенчәләре һәм мөселман кешесенең вазифалары хәтта биш яшьлек бала да аңларлык телдә язылган. Автор дусларча һәм юмор хисе белән яшь укучыларга мөрәҗәгать итә һәм материал аңлаешлы булып, хәтердә калсын өчен, заманча сторителлинг (хикәяләү) техникасын куллана.

«Клад для маленьких мусульман» – безнең кечкенә балаларыбыз өчен төсле рәсемнәр белән бирелгән беренче мөселманча белешмә-энциклопедия. Анда сез күп кенә кызыклы, гадәти булмаган һәм күңелле мәгълүмат белән таныша аласыз. Сезне төрле илләр буйлап сәяхәт, тәмле рецептлар, гадәти булмаган биремнәр көтә. Болар барысы да көндәлек тормышта кирәк була торган дини белемнәр белән бергә үрелеп бара.

Бу китап миллионлаган сораулар бирүче балаларыбыз өчен файдалы булыр дип ихластан өметләнәбез.

Китапны “Хозур” нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм дистанцион рәвештә заказ бирергә мөмкин.

Кибет: Казан шәһ., Тукай ур., 36нчы йорт. Тел.: +7 960 072-74-63;
Склад: Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт. Тел.: +7 (966) 250-00-09;
Интернет-кибет: huzurshop.ru

Ләйсән ШӘЯХМӘТОВА:

“Телләр өйрәтү – изге эш”

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның туган телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү, республиканың күпмилләтле халкы бердәмлеген нык ыту максатларында, җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә 2021 ел – Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде.

Татарстан – телләр сәясәтен уңышлы алып бара торган республикаларның берсе. Татар телен дөнья күләмендә популярлаштыру буенча бүгенге көндә зур эшләр башкарыла, телебезне өйрәнәләр, телебез белән фәнни яктан кызыксыналар.

Татарстан мәчетләре каршындагы татар теле курсларын барыбыз да беләбез. Казан (Идел буе) федераль университеты да татар телен таныту юнәлешендә төрле чаралар үткәрә. “Ана теле” онлайн мәктәбе, “Каюм Насыйри институты” һәм 2011 елдан башлап киң катлам халык өчен оештырыла торган түләүсез татар теле курслары шуның дәлиле булып тора.

Бүген без шушы татар теле курслары хакында тулырак мәгълүмат алу максатыннан Казан (Идел буе) федераль университеты доценты, филология фәннәре кандидаты Ләйсән Шәяхмәтова белән әңгәмә кордык.

– Ләйсән Хәбировна, татар теле курслары кайчан барлыкка килде һәм аның барлыкка килүенә нәрсә сәбәпче булды?

– Мондый курслар инде берничә ел элек үткәрелгән иде. Алар телләрне саклау, үстерү һәм пропагандалауга юнәлдерелгән дәүләт программасы кысаларында үткәрелә. Бу курслар татар телен өйрәнергә теләүчеләр өчен оештырыла һәм алар түләүсез. Моннан берничә ел элек үткәрелгән курсларга 800ләп кеше язылган иде. Без беркемгә дә киртә куймадык, килгән барлык кешене дә кабул иттек. Быел 500ләп кеше килде. Әлбәттә, алар арасында төрле кешеләр бар: өлкән яшьтәгеләр, урта буын (алар үз вакытында татар телен өйрәнмәгән булганнар), бик күп яшьләр (студентлар) һәм тагын чит милләт вәкилләре. Мәсәлән, минем төркемгә 24 кеше йөри. Алар арасында Иран кешесе дә бар. Һөнәре буенча ул – инженер. Ул шушы курсларга бик теләп һәм кызыксынып йөри. Шунысы кызык: татар һәм фарсы телләренең уртак сүзләре ягъни фарсы алынмалары бар. Мәсәлән, дивар, китап. Ул аларны бик тиз белеп ала һәм шуңа да аңа татар телен өйрәнү җиңелрәк бирелә.

– Курсларга рус милләтеннән йөрүчеләр күпме?

– Әйе, күп. Мәсәлән, минем төркемдәге 24 кешенең 10сы рус милләтеннән.

– Татар телен өйрәнүгә ихтыяҗ аларда нилектән барлыкка килде икән?

– Аларның кайберәүләре татар кешесенә кияүгә чыккан яки татар кызына өйләнгән. Кайберәүләре, бигрәк тә яшьләр, дуслары татар милләтеннән булып, дусты белән аралашырга теләп татар телен өйрәнә. Сембер якларыннан булган бер егет исә татар телен үзе өчен өйрәнә.

– Бүгенге көндә татар курсларына йөрүчеләрнең якынча санын әйтә аласызмы?

– Казанда оештырылган курсларда 500 кеше, ләкин бу әле Казан буенча гына, моннан тыш регионнарда да бар. Безнең әле К. Насыйри исемендәге институтның регионнардагы үзәкләре бар. Шул үзәкләрдә, безнең аеруча актив эшләүче методистларыбыз якынча унбишәр кеше җыйды. Аларда 100 кеше дип алсак, димәк, барлыгы 600 кеше.

– К. Насыйри исемендәге институт хакында тулырак әйтеп үтсәгез иде.

– К. Насыйри исемендәге институт – бу виртуаль институт. Шулай ук телләрне саклау, үстерү һәм пропагандалауга юнәлдерелгән дәүләт программасы кысаларында оешкан. Бу институтның төп максаты – чит регионнарда да татар телен, мәдәниятын пропагандалау, татар телен үстерү һәм өйрәтү. Безнең ике үзәк чит илдә – Казахстанда һәм Кыргызстанда. Тагын Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург, Уфа, Пенза, Чабаксар, Ульяновск, Тобол һәм Самара шәһәрләрендә. Бу курсларда методистлар татар теленә өйрәтәләр. Курслардан тыш анда мәдәни-агарту чаралары үткәрелә. Татар Конгрессы белән берлектә “Татарча диктант” язабыз, онлайн дәресләр алып барабыз, ягъни һәр үзәк өчен атна саен бер сәгатьлек дәресләр үткәрелә. Аннан тыш фәнни-популяр лекцияләр укыла. Пандемия чорында дистанцион платформаларда эшләү буенча без шактый тәҗрибә тупладык. Мәсәлән, элек без Казахстанның бер генә шәһәре белән эшләгән булсак, хәзер исә, “бүген дәрес була”, дип анонс бирүгә, Казахстанның төрле шәһәрләре дә безгә кушыла ала.

– Казахстанда яшәүчеләр татар телен өйрәнә алалар. Ә Аурупа илләрендә яшәүче милләттәшләребез татар телен өйрәнергә теләк белдергәннәре бармы? Алар белән эш ничек алып барыла?

– Әлбәттә, теләк белдерүчеләр бар. Аурупа илләре ераграк булганга, алар белән эшләве катлаулырак. Шуңа да без иң элек эшне элеккеге СНГ илләреннән башладык. Хәзерге вакытта Финляндия, Төркия белән сөйләшүләр алып барыла. Шулай ук әле “Ана теле” платформасына да язучылар бик күп. Италиядән, Австралиядән, Франциядән дә язалар.

– Сезгә татар теле курсларында укыту ошыймы? Ашкынып киләсезме?

– Миңа татар теле курсларында эшләү, гомумән, татар теле укыту бик ошый. Мин күбрәк татар телен бөтенләй белмәүче аудитория, ягъни татар телен башлангыч дәрәҗәдән өйрәнүчеләр белән эшлим. Әйткәнемчә, татар телен укыту миңа бик ошый. Бу өлкәдә мин инде 2002 елдан бирле эшлим һәм ничә елдан бирле эзләнеп, төрле формаларны кулланып һәм күнегүләр эшләтеп карап, үземнең бер юлым булдырылды, шул нигездә дәреслек эшләнелде (“Татарский язык для начинающих”). Шуңа таянып эшлибез һәм мин нәтиҗәләрен күрәм, сөенәм, чөнки бу бик кирәкле, изге эш.

■ Әңгәмәне **Ленар ХАММАТОВ** оештырды

26 нчы апрель – Туган тел көне

Татар теле

Татар телем, туган телем,
Мәңгелек телем минем.
Татар теле белән ямьле,
Татарстаным минем.

Татар теле күңелләргә
әниләрнең
Күкрәк сөтеннән иңгән.
Чагыштырсаң татар телен,
Табылмаслардыр тиңнәр.

Татар моңы халкыбызның
Күңел түреннән чыга.
Татар моңы юлдаш булды,
Юлда һәр юлаучыга.

Татар теле гомер буе
Иң кадерле, газиз тел.
Туган теленне хөрмәтлә,
Башка телләрне дә бел.

Татар булсаң, татар
бул син,
Кеше таңнар калырлык.
Әдәп-әхлак, эш-гамәлең
Тарихларда язарлык.

Исламия УСМАНОВА

Фин татарларының “Тампере шәһәре Төрекләр җәмгыяте”н төзүе

XIX гасыр азагында Бөек Финляндия кенәзлегенең сәнәгать башкаласы булган Тампере шәһәрендә татар җәмәгатьчелеге оеша башлый. Моңа аеруча да 1876 елда Петербург-Тампере тимер юлының ачылуы тәэсир ясый. Элек Петербургта сәүдә иткән асламчы-татарлар, яңа сатып алучылар эзләү нияте белән, тимер юл аша Тампере шәһәренә килә. Сату итә торган төп товарлары тукыма була. Көчле конкуренция булмау сәбәпле, күпләр тиз арада байыйлар.

Нигездә алар: Нижгар губерниясенең Сергач өязендәге Актүк (Актуково) татар авылыннан булган кешеләр була. Шулай ук Мәдәнә (Медяна), Уразавыл (Уразовка), Атяр (Антяровка), Суыксу (Ключищи), Кызымавыл (Кузьминка), Кадымавыл (Кадомка), Чүмбәли (Чембилей), Семоцки (Семёновка), Рбишча (Рыбушкино) исемле күрше авылларыннан да күченеп килүчеләр булган.

Революциягә кадәр Тампере шәһәренең татар җәмәгатьчелеге үзенә имам һәм укытучы итеп Галәветдин Габбасовны чакырган. 1910 елларда балаларны укыту имам йортында алып барылган, анда шулай ук җомга һәм бәйрәм намазлары укытылган. Галәветдин Габбасов туган җире Казанга кайтып китәргә мәҗбүр булганнан соң, мулла һәм укытучы итеп, Гыйбадулла Мортазин (1895-1968) чакырылган. Тамперега ул 1923 елны Алман иленнән килгән һәм 20 елдан артык гомерен җирле татар җәмәгатьчелегендә мәгариф эшчәнлеге алып баруга багышлаган.

Берлинда Гаяз Исхакый тарафыннан нәшер ителгән “Яңа милли юл” татар иммигрантлары журналының бер санында (1931 ел, №2) Гыйбадулла Мортазин Тампере татар җәмәгатьчелегенең кызыгырлык булмаган киләчәге турында хәбәр итә. Ул җирле җәмәгатьчелекнең, бигрәк тә яшь буын вәкилләре булучыларның, мәдәният һәм динне саклап калуда мөмкинлекләре аз булуы хакында яза. Әгәр хәлләр үзгәрмәсә, аларга тулысынча ассимиляцияләшү янаганы турында әйтә. Гыйбадулла Мортазин татарларга үз көчләренә ышанырга һәм мәдәниятне, динне, телне саклау белән шөгыльләнә торган социаль җәмәгатьчелекне барлыкка китерүнең кирәклегенә басым ясый.

● *“Фин татарлары. “Галиябану” спектакленнән. 1946 елның 19 нчы феврале. Мүәззез Байбулат китабыннан”*

Баштан бу эшләрне җәмәгатьчелекнең хатын-кызлары башлап җибәрә. 1934 елда Мәһрүсә Вафина (Mehrusa Wafin) тырышлыгы белән «Яшь ханымнар оешмасы» барлыкка китерелә. 1935 елның 6 нчы гыйнварында, Рамазан бәйрәме вакытында, бу оешма тарафыннан зур чара оештырыла. Мәһрүсә Вафина милли үзаңны, мәдәниятны, чит мәдәният әйләнәсендә телне саклауның кирәклеге турында сөйли. Бу оешма рәсми рәвештә теркәлгән булмаса да, нәкъ менә ул “Тампере шәһәре Төрекләр җәмгыяте” барлыкка килүгә сәбәпче була.

“Тампере Ислам мәхәлләсе”нең рәсми теркәлүенә кадәр “Тампере шәһәре Төрекләр җәмгыяте” җирле җәмәгатьчелекнең тормышында әһәмиятле роль уйный. Ул һәрвакытта да Тампере мөселманнарына дини һәм милли бәйрәмнәр оештыра. Алар шулхәтле популяр булып китә ки, хәтта бу чараларга Финляндиянең барлык татарлары килә.

● *Балалар хоры. Шагыйрь Габдулла Тукайга багышланган кичә, Hospiz Emmaus банкет залы, 1967 ел. Мүәззез Байбулат китабыннан*

“Тампере шәһәре Төрекләр җәмгыяте” («Tampere Türkler Birligi») 1935 елда Финляндия дәүләт органнары тарафыннан барлыкка китерелә һәм рәсми рәвештә теркәлә. Җәмәгатьчелекне барлыкка китерүнең төп максаты: үзеңнең тарихың белән танышу һәм милли мәдәниятне саклау. Җәмәгатьчелектә зур рольне Гыйбадулла Мортазин башкара, нәкъ менә ул һәрвакытта диярлек үз өстенә оештыручы һәм мәдәни программаларны алып бару вазифаларын ала. Нигез салынганнан бирле һәм 1954 елга кадәр ул җәмәгатьчелекнең алыштыргысыз рәисе була. Әгәр дә беренче елларда җәмәгатьчелекнең рәсми әгъзалары булып чама белән 50 кеше торса, 1961 елда аларның саны 119 га җитә. Күп еллар дәвамында “Тампере шәһәре Төрекләр җәмгыяте” җирле татар җәмәгатьчелегенең мөһим элементы булып тора.

■ **Мөхсин НУРУЛЛА** язмасы,
islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә

Рамазан ае хатирәләре

Рамазанны гөнаһлардан котылу, Аллаһыга якынаю, камилләшүгә ирешү ае, дибез. Рамазан – безнең өчен тагын бер мөмкинлек, форсат та ул.



Без кечкенә чакларда мәчетебездә тәравих намазлары төгәлләнгәннән соң, соңгы кичтә әбиләребезнең имам сөйләгәннәрен тыңлап, елап утырганнарын күрә идек. Әле хәтеремдә, балалыгым белән аңламыйча, өйгә кайтып, әни фәлән әби никтер елады да елады, нәрсә булган икән, дип сораганым. Ул әбиләрнең күбесе мәрхүм инде (Раббым урыннарын җәннәттә кылсын, язганнарым дога булып барсын). Шулвакытта миңа әни: "Кызым, алар: "Аллаһыга шөкер, тагын бер ел Рамазан аен каршы алып, уразалар тотып, тәравихларга йөри алдык. Киләсе елларыбызда да шулай Рамазан айларын күрү насыйп булырмы икән?" – дип елыйлар", – дигән иде.

Хәзер бу тәравихларга күп еллар үтте, ул вакытта йөгерә-йөгерә мәчеткә килгән балалар хәзер үзләре әти-әниләр. Менә хәзер без ул вакытта әбиләребезнең, олы буын вәкилләренең ник елаганнарын аңлыйбыз, чөнки нәкъ менә хәзер, балачактагы Рамазаннан, тәравихлардан аермалы буларак, без Рамазан аеның бер мөмкинлек, форсат икәнен аңлап яшибез. Еллар узган саен аның кадере арта гына бара. Без хәзер елга бер генә килә торган Рамазан ае бәрәкәтендә яшәгәндә, Раббыбыздан бу айларны әле бик күп еллар каршы алу бәхетенә лаек булсак иде, дип дога кылабыз. Безнең өчен Рамазан – ул нур, яктылык, үзебезне тәрбияләү, уйларыбызны, тормышыбызны тагын да яхшы якка үзгәртү, ике дөнья бәхетенә ирешү ае. Әлбәттә, аны дөрес итеп үткәргән вакытта, без киләсе Рамазанга кадәр аның бәрәкәтендә гомер итәчәкбез. Рамазанның ләззәтен татыган кешегә аны озатып җибәрү кыен. Монда Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисе искә төшә: "Әгәр кешеләр Рамазан аеның бөтен хасиятләрен, савапларын белсәләр, бөтен ел әйләнәсе Рамазан ае булуын теләрләр иде" (имамнар Әт-Табәрани, Бәйһакый).

Рамазан ае белән бәйле балачак хатирәләрен барлаганда шунысын да искә алыйм, безгә кечкенә вакытта: "Рамазан ае азагында "Кадер киче" дип атала торган төн бар. Ул төнне күк капуслары ачыла, бөтен җир яп-якты була. Шулвакытта кылган барлык догалар кабул була. Ул төнне шундый тыныч булыр, җил дә исмәс, ул башка төннәрдән аерылып торыр", – диләр иде. Һәрберебезнең бу төнне күрәсе, каршы аласы, теләк телисе килә иде, билгеле. Әгәр иртән мәктәпкә килгәч, берәрсе: "Бүген төнлә "Кадер киче" булган икән", – дисә, бераз күңелсезләнеп кала идек. Их, быел да күреп булмады! Һәм зур өметләр белән киләсе Рамазанны, бөтен теләкләр кабул була торган төнне – "Кадер киче"н көтә идек.

Менә шундый риясыз, ихлас булган сабый чакта Рамазан аен көтүебез. Ул Рамазан айлары инде кабатланмас. Без сабыйларча көткән, әбиләр елап озаткан Рамазан айлары...

■ **Айсылу ЮЛДАШЕВА**

Иң начар әйбер

Нәширван хаким өендәге җыелышта өч хикмәт иясе дә катнашкан. Сөйләшү барышында иң начар әйбернең нәрсә булуы хакында сүз купкан.

Греклы хикмәт иясе:

– Иң авыр һәм начар әйбер – ул мохтаҗлыкта картаю, – дигән.

Һиндлы хикмәт иясе:

– Иң авыр һәм начар әйбер – кайгы-хәсрәт белән бергәлектә авыру килү, – дигән.

Бәзер Җөмһүр исемле хикмәт иясе:

– Иң авыр һәм начар әйбер – начар гамәлләрең күп булган хәлдә үлем килү, – дип әйткән.

Калган хикмәт ияләре Бәзер Җөмһүрнең хаклыгын танып, аның фикерен кабул иткәннәр.

Нәсыйхәт:

Бу, чыннан да, шулай, чөнки калган хикмәт ияләре искә алган хәлләрдән чыгу юлы бар, алардан котылып була. Әмма үлеме якынаеп килгән чакта бик күп начар гамәлләре булган кешенең хәле начар. Аның начарлыкларын изгелекләргә алыштырырга вакыты юк. Әгәр инде начар гамәлләренең берсе көферлек булса, моннан бөтенләй дә качу юлы булмас. Аллаһым сакласын!

Итагать һәм буйсынмау

Бер тәкъва иясе болай дип сөйләгән: "Берьюлы мин йоклап киткәч, мондый төш күрдем: Кыямәт көне җитте һәм кешеләр хисап тотканнан соң, кайберәүләре җәннәткә, ә икенчеләре җәһәннәмгә китте. Мин җәннәт капкалары янында торучыларга килеп: "Йә җәннәт әһелләре! Нинди гамәл өчен монда эләгү хокукына ия булдыгыз?" – дип сорадым. Алар: "Бу хокукка без Рәхимле Аллаһыга итагатьле булганга, ә шәйтанга буйсынмаганга күрә лаек булдык", – дип әйттеләр. Шуннан соң мин җәһәннәм капкалары каршында торучы кешеләргә килеп: "Йә җәһәннәм әһелләре! Сезне монда нәрсә алып килде?" – дип сорадым. Алар: "Безне монда шәйтанга буйсыну һәм Аллаһыга итагать итмәү китерде", – диделәр.

Шулвакытта мин җәннәт белән җәһәннәм уртасында торган кешеләр төркемен күрдем. Һәм алардан:

– Нигә сез җәннәт белән җәһәннәм уртасында көтеп торасыз? – дип сорадым.

Алар:

– Безнең гөнаһларыбыз да, бераз изгелекләребез дә бар. Гөнаһлар безгә җәннәткә керергә бирми, ә изгелекләр җәһәннәмгә, – дип җавап кайтардылар.

#Ике теләк

Вәһеб бине Мөнәббиһ рахимәһуллаһи болай дип сөйләгән: "Дүртенче кат күктә ике фәрештә очрашкан. Берсе икенчесеннән: "Каян киләсең?" – дип сораган. Ул: "Бер яһүди балык ашарга теләгән иде. Миңа диңгездәге ул теләгән балыкларны аңа таба җибәрү әмер ителде. Мин бу әмерне үтәп кайтып киләм. Ә син каян киләсең?" – диде. Икенче фәрештә: "Бер тәкъва иясе зәйтүн мае теләгән иде. Мин шуны салып кайтып киләм", – дип җавап биргән.

Нәсыйхәт:

Аллаһы Тәгалә бу дөньяда кяферләргә ни теләсәләр, шуны бирә, чөнки дөнья тормышы – аларның бердәнбер ризыгы, өлеше. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән: **"Бөтен кешеләр [көфергә тартылып] бер өммәт булу куркынычы булмаса, Рахманны инкяр иткән [кяфер] кешеләр өчен өйләренә көмештән түбәләр һәм алар шуларга менә торган [көмеш] баскычлар ясар идек. Өйләренә [көмеш] ишекләр һәм алар таянып ятачак ятаклар да".**

«Зүхъруф / Зиннәтләнү», 43:33-34

Әмма кяферләрнең киләсе тормышта бернинди дә ризыклары, өлешләре юк. Шунлыктан аларның теләкләре дөнья тормышында канәгатьләндерелә.

■ **«Рухуль Бәйан»** китабыннан

Гозәер галәйһиссәлам кыйссасы

Гозәер бине Җәрва галәйһиссәламне Исраил уллары аеруча якын иткәннәр һәм яратканнар. Кабиләдәшләре халыкта онытылган Тәүратны яттан белгәнгә күрә аңа иман китергәннәр.

Гозәер галәйһиссәлам бер гасырлык гомере дәверендә берничә үлем һәм кабаттан терелү кичергән. Аллаһы Тәгалә Гозәер галәйһиссәламне йөз елга тормыштан мәхрүм иткән, ә соңыннан, кешеләр үлгәннән соң Раббыбызга ничек кайтасыларын күрсәнәр өчен, гаҗәеп рәвештә үз халкына кире кайтарган. Коръәни Кәримдә бу хакта түбәндәгеләр әйтелә:

«Яки нигезенә кадәр җимерелеп беткән авылдан үткән кеше турында [ишеттеңме?]. Ул: «Үлгәненнән соң Аллаһы моны ничек терелтер икән?» – дигән иде. Аллаһы [шул урында] йөз елга аның җанын алды, шуннан [йөз ел үткәч] терелткән иде. Ул [Аллаһы Тәгалә аңардан]: «[Син монда] Күпме [вакыт] тордың?» – дигәч, ул исә: «Бер көн яки көннең бер өлеше [кадәр аз бер вакыт] тордым», – дигән иде. Ул [Аллаһы Тәгалә]: «Түгел, син [биредә] йөз ел [үле килеш] тордың. Ашамлык һәм эчемлекләреңә кара, [күп вакыт үтүгә карамастан, алар бозылып] үзгәрмәгәннәр. Инде [сөякләре череп һәм таралып яткан] ишәгеңә кара. [Безнең өстен көчебезне аңласыннар һәм] Сине кешеләр өчен бер билге [һәм гыйбрәт] итәргә дип [кире терелттек үзеңне]. [Хәзер] Сөякләрне ничек җыйганыбызны, шуннан соң аларга ит кундырганыбызны кара», – дигән иде. [Ишәге күз алдында терелгәнне күргәннән соң, Аллаһының кодрәте] Аңа күрсәтелгәч, ул: «Һичшиксез, Аллаһының [җанны алу белән терелтүне дә исәпкә алып] һәрнәрсәгә кодрәтле булганын [хәзер инде күреп тә] беләм», – диде».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:259

«Аллаһы Тәгалә әлеге шәһәрне тулысы белән юк иткәннән соң, аны ничек яңадан торгыза ала икән?» – дигән уйлар белән йөрүче кешене Гозәер галәйһиссәлам дип белерсез. Бу уйланулар һичнинди көферлек тә, динне кире кагу яки иман китерүгә шикләнү гамәле дә түгел, ә бәлки Аллаһының кодрәтен тулы рәвештә аңлау талпынышы булган. Чынлыкта, Гозәер галәйһиссәлам изге, гадел, тугры кеше булган. Бу фикерләре дә башына Навуходоносор җимергән Кодес хәрабәләре янынан узган мәлдә килгән.

Навуходоносор – Бабил патшасы. Аны Аллаһы Тәгалә Исраил уллары на илаһи боерыклардан баш тарткан, пәйгамбәрнең нәсыйхәтләренә колак салмаган һәм золым кылганнары өчен җәза сыйфатында җибәргән. Чиксез гаскәргә ия булган патша, гаепсез кешеләрне үтереп Шамны һәм Иорданияне яулап алган, шулай ук Кодес шәһәрен буйсындырган. Нәкъ менә аның тарафдарлары Әл-Әкъса мәчетен җимереп, Кодес бакчаларын юкка чыгарганнар.

Шушы күренешләрне Гозәер галәйһиссәлам ишәк өстенә утырып күзәтеп барган. Кодес җирлегенә килеп җиткәч, ул бер ташландык бакча янында туктаган, ишәгенең йөген бушатып, агачка бәйләп куйган. Күз алдына хәрабәләр булып калган шәһәр, җимерек өйләр, таланган бакчалар килеп баскан...

Арып һәм ачыгып, Гозәер галәйһиссәлам бераз инҗир һәм йөзем җыйган. Инҗирнең бер өлешен ашап, йөземнең суын сыгып эчеп, ул агач астына утырып, җимерелгән йортларга, начар хәлгә килгән юлларга һәм кеше сөякләренә карап, Аллаһы Тәгалә әлеге таланган һәм үле хәлгә килгән җирне ничек итеп терелтә алачак, дигән уйларга чумган. Әлеге уйлардан ул үзе дә сизмәстән йокыга киткән. Бу йокыдан ул үлем халәтенә күчкән: Аллаһы Тәгалә Гозәер галәйһиссәламне тормыштан мәхрүм иткән, әмма аның гәүдәсен һәм ашамлыкларын таркалудан саклаган, кешеләр һәм хайваннар күзеннән яшергән.

Йөз елдан соң Аллаһы Тәгалә Гозәер галәйһиссәламне янәдән терелткән. Әмма, күзләрен ачкач, билгеле, ул бу кадәр озак вакыт буе үле килеш ятуын аңламаган. Бары иртән генә ул үзенең йокыга киткәнен исенә төшергән, ә уянгач, кояшның әле баемаганын күргән. Шуңа да иртәдән кичкә кадәр йоклаганмын икән, дип нәтиҗә ясаган. Җитмәсә, аның өзеп алган инҗире һәм сыккан йөзем суы да бозылмаган булган.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

«[Син монда] Күпме [вакыт] тордың?» – дигәч, ул исә: «Бер көн яки көннең бер өлеше [кадәр аз бер вакыт] тордым», – дигән иде. Ул [Аллаһы Тәгалә]: «Түгел, син [биредә] йөз ел [үле килеш] тордың. Ашамлык һәм эчемлекләреңә кара, [күп вакыт үтүгә карамастан, алар бозылып] үзгәрмәгәннәр. Инде [сөякләре череп һәм таралып яткан] ишәгеңә кара. [Безнең өстен көчебезне аңласыннар һәм] Сине кешеләр өчен бер билге [һәм гыйбрәт] итәргә дип [кире терелттек үзеңне]. [Хәзер] Сөякләрне ничек җыйганыбызны, шуннан соң аларга ит кундырганыбызны кара», – дигән иде».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:259

Ишәктән бары череп беткән сөякләр генә калуга карамастан, Аллаһы Тәгалә аны да терелткән. Бу хәл Гозәер галәйһиссәламнең күз алдында булган. Гаҗәпкә калып, ул болай дип әйткән:

«Һичшиксез, Аллаһының [җанны алу белән терелтүне дә исәпкә алып] һәрнәрсәгә кодрәтле булганын [хәзер инде күреп тә] беләм».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:259

Аллаһының кодрәтен дәлилләгән әлеге бөек күренешләрне күзәткәннән соң, Гозәер галәйһиссәлам үзенең ишәгенә атланып Кодес шәһәренә юнәлгән. Шәһәргә керү белән, ул биредә барысы да үзгәреп беткәнен күргән. Каршыга чыккан кешеләр дә, йортлар һәм урамнар да, шәһәр биналары һәм юллар да аңа таныш булмаган. Бу вакытта Навуходоносор үлгән, Фәләстыйн илбасарлардан азат ителгән, ә әсирлеккә төшкән кешеләр ирекка чыккан һәм кире кайткан булганнар. Шулай итеп, шәһәрдә янә тормыш кайный башлаган.

(Дәвамы бар)

■ **Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
Татарстан Республикасы мөфтие

Кайнар диңгез юлы

(Повестьтән өзек)

(Азагы. Башы алдагы саннарда)

...Җомга намазыннан соң, хәзрәт мәчет эшләре белән китте. Рәйсә абыстай үзенә тапшырылган вазифаларга кереште. Мәдрәсә ягына кереп, шәкертләрнең хәлләрен сорашты. Аскы катта урнашкан кибеткә узды... Мәчетнең беренче катында ашханә эшли. Аның урамнан керә торган ишеге дә бар. Көннең кайсы сәгате булуына карамастан, ашханәдә кеше һәрвакыт тулып тора. Хәләл ризык белән тукланырга теләүчеләрнең күп булуына куана абыстай. Никах мәҗлесләре дә шушы ашханәдә уздырыла.

Ул өстәл янына барып утыруга, мәдрәсәдә мөгаллимәсе Флера апа белән аның группасында укучы Фәния, Зәйтүнә, Әлфия апалар килде. Ягымлы итеп, абыстайны үз итеп, яратып исәнләштеләр дә:

– Корбан бәйрәмендә чалырга сарыкларга заказлар җыя башладыгызмы әле, абыстай? – дип сорадылар.

– Әйе, – дип, сумкасыннан дәфтәрен алып, заказ бирүчеләрнең исемлеген күрсәтте.

Быел безгә биш сарык кирәк булачак. Корбан чалдырырга кирәклеген балаларыбыз гына түгел, оныкларыбыз да аңлый башлады, әлхәмдүлилләһи шөкер. Яшь вакытта кайлардан сарык табыйк икән дип, борчылып йөри идек. Менә бит, нинди рәхәт заманнар килде. Мәчеткә заказ гына бирәбез, чалып, эшен бетереп бирәләр. Аллаһның рәхмәтләре яусын, – диде Фәния.

– Арендага бина алып, сарык фермасы ясау бик дөрес булды, – дип, Флера апа ике баш сарыкка яздырды.

– Безнең гаиләләргә өчәрне языгыз, абыстай, – диде Фәнзүлә белән Әлфия.

– Апалар, әйдәгез, бергәләп чәй эчик, – диде Рәйсә абыстай.

– Бүген җомгада ике мәеткә җеназа намазы укылды, белгәннәрегез түгел идеме? – дип сорады Флера.

– Икесе дә өлкән кешеләр булган, балалары озата килде. Мәчет янында мәетханә булуына бик куандылар. Берсе – әтисен, икенчесе әнисен соңгы юлга дини кагыйдәләр буенча озатылуына куанып, кат-кат, рәхмәт әйттеләр. Зиратта каберне дә үзләре казыйсы түгел ич, махсус кешеләр хезмәт күрсәтә. Таһир хәзрәт Себер җирендә ислам динен югары дәрәҗәгә күтәрде. Бала тууга исем кушудан башлап, һәр мөселманны ислам дине кануннары белән яшәргә өйрәтә һәм соңгы юлга озату өчен дә барлык шартларны тудырды, – диде Әлфия.

– Таһир хәзрәт белән абыстай килеп эшли башлаган заманнарда монда диннең исе дә юк иде әле. Хәзер Сургутта мәчеткә килми торган татарлар калмагандыр. Җомга намазында гына бер мең биш йөз кеше катнаша.

– Гаетләрдә гыйбадәт кылучылар саны унар меңгә җитә ич. Мәчет биләмәсендә алма төшәр урын калмый. И, кардәшләр, нинди заманда яшибез, Аллаһка хисапсыз шөкер, – дип, Флера апа мәдрәсәгә укырга йөрүчеләрнең дә елдан-ел арта баруын әйтте.

Рәйсә абыстай дусларының сүзләренә рәхмәтен әйтеп тыңлап утырды да:

– Менә шуның өчен дә, Сургутта тагын бер мәчет төзү өчен, җир участогы алырга йөри хәзрәт. Халык саны артып тора, бер мәчеткә генә сыешмыйлар, – диде дә, үзеннән-үзе хисләнеп сөйләп китте. – Гаетләрдә гыйбадәт кылучыларның мәчет биләмәсенә генә сыешмыйча, урамнарда укыганнарын күргәч, хәзрәт белән минем күңелнең нинди иланы рәхәтлек кичергәнен белсәгез иде сез! Намаз укучылар сафында мәчеткә ярдәм итүче җитәкчеләребез дә башларын сәҗдәгә ияләр бит. Аллаһ каршында һәркемнең тигез икәнен алар да аңладылар. Гомеребез бушка узмады, Аллаһ юлында ихлас күңелдән хезмәт иткәнебезне Себер җирендә эшләүчеләр дөрес итеп кабул иттеләр, – дигән уйдан җаныбыз җылына. Менә шул җылылыкның кайнарлыгы безне Себер салкынынан саклый да инде, кардәшләрем. Тормышыбызның иң кыен чорында янәшәбездә сез булдыгыз, – дип әйтеп бетерүгә, Рәйсәнең телефоны чылтырады. – Авылдан Гәүһәрия сеңлем, – дип, колагына куйды. Ул сөйләшкән арада мөслимәләр чәйләрен эчеп бетереп, бер-бер артлы таралыштылар.

– Апай, җиденче ноябрь көнне авылда шәҗәрә бәйрәме үткәрәбез. Барыгызның да кайтуы мәҗбүри, яме. Безнең нәсел җебен 1678 елдан башлап өйрәндем. “Татарлар” телевизион тапшыруына әзерлиләр. Республиканың Кадрия Идрисова җитәкчелегендәге “Ак калфак” иҗтимагый оешмасы хатын-кызлары килә. Бик яхшы булачак, апаем.

Гәүһәриянең үзе йомшак, үзе үтемле итеп чакыруына каршы килергә мөмкинме соң!..

– Әлбәттә, кайтабыз, сеңлем, – дип кенә әйтә алды.

...Гәүһәриянең чакыруы Рәйсә абыстайның күңелен авылга кузгатты. Югыйсә, Сара янына Казанга елына бишәр тапкыр да кайтып киләләр. Шәҗәрә бәйрәменә дип чакыру аның һәр туганын аерым-аерым күз алдына китереп бастырды...

Ак яулыгын аркасына җәеп салып бәйләгән әнисен уйлагач, бите буйлап кайнар яше тәгәрәде. Авылда аннан да гыйлем, тәкъва кеше тагын бармы икән? Әнисенең тирән мәгънәле, зирәк фикерләрен, гыйбрәтле сүзләрен, иң кирәкле догаларын һәрчак бер дәфтәргә язып барды. Башта ул аларны мәҗлесләрдә вәгазь сөйләгәндә кулланды. Аннары дәфтәре калынайгач, “Иң кирәкле догалар” дип, китап итеп чыгарып, туганнарына, дини кардәшләренә таратты...

Туган җирнең, туган телнең кадерен белү өчен, аннан бераз аерылып тору кирәк икәнлеген, Рәйсә Сургутка килеп яши башлауга аңлады. Базарда, урамда татарча сөйләшкән кеше дә туганы кебек якын кешегә әйләнде. Кешенең кадере аны югалткач, туган якның кадере аннан ераклашкач беленә икән, дип, ничәмәничә тапкырлар кабатланып, күңеле аша уздырды. Бер аның гына түгел, читтә яшәүчеләрнең уртак сагышы бу...

– Абыстаем, ник моңаеп уйга калдың? – дип, аның янына Таһир хәзрәт килеп утырды. Гомер иткән абыстаеның йөзенә генә карап алды да: – Әйтмәсәң дә, күзеңнән күрәм, тагын бер туганыбыз авылга мәчет ачарга чакырдымы әллә?

“Шәҗәрә” бәйрәме турында әйткәч, хәзрәтнең дә йөзенә кояш нуры иңгәндәй булды.

– Туган як белән ике араны ныгытып торучы туганнарыбыз булуы белән ничек бәхетле без! Барысы да динле-иманлы, хаҗ сәфәрләренә барып торалар. Без – дөрес юлда яшибез, кешенең иң олы куанычы шушы бит. Минем дә сиңа шатлыклы хәбәрем бар: Сургутта икенче мәчет төзергә бик уңайлы урыннан җир бирелде.

Рәйсә абыстай иренең күзенә карап торды да, әйтергә теләгән сүзен башта күңеле иләге аша үткәрде.

– Халык бер мәчеткә генә сыймый, икенчесе кирәклеген аңлыйм. Тик хәзрәтем, таякка таянган картлык көнебез җиткәнче, туган якка кайтып урнашырбыз инде. Синең сызган юлыңнан атлаучы улыбыз бар, яңа мәчетне яшьләр кулына тапшырырсың, – диде җайлап кына, ипләп кенә, ире күңеленә юл табарга тырышып.

Таһир хәзрәтнең йөзе бер яктырды, янә кырысланып алды. Ул карашын тәрәзәгә таба юнәлдерде. Күңелендә егерме ел элек йөрәгенә сеңеп калган вакыйгалар кузгалып куйды. Илле градуслы салкын кыш. Ул, мәчет төзергә җир сорау өчен, иртәнге сәгать биштә поезддан Салихард шәһәренә килеп төште. Каршы алучы юк. Җиргә куе томан төшкән, машина фарасы да күренми. Башта борчылуданмы, сизмәде салкынны. Ул вокзал каршында көннең ачылганын көтеп, әрле-бирле йөри башлады. Каршы алырга килергә тиешле кешеләр, берәр сәгатьтән генә килеп җиттеләр. Салихард шәһәренә, мәчет салырга яхшы урын алу өчен, өч тапкыр барды. Илле-алтмыш градуслы салкынга каршы торырга да ияләшә икән адәм баласы...

– Тормышыбызның бик авыр һәм катлаулы вакытлары бар иде, абыстаем. Аллага шөкер, без ул чорны уздык. Себер салкыны мине чыныктырды, чын ир-егет ясады. Туган якка кайту – читтә яшәгән һәркемнең олы хыялы. Тәкъдиребезгә язылган булса, кайтырбыз. Туган якта – безнең нәсел тамырыбыз исән...

■ **Гөлсинә ГАЛИМУЛЛИНА**

Хөрмәтле радиотыңлаучылар!

«Азан» радиосын azan.fm сайтында яки «Азан» радиосы рәсми кушымталары аша тыңлагыз. Моның өчен түбәндәге QR-код аша үтегез яки App Store (iPhone өчен) һәм Google Play Market (Android өчен) платформаларыннан «Азан радиосы» кушымтасын йөкләп алыгыз.

QR – кодлар:

Android өчен:

iPhone өчен:

Сайт: azan.fm
Инстаграм: azan.fm
Вконтакте: azanfm
Телеграм-канал: azanfm

Почта: radio@azan.fm
Тел.: 8 (843) 598-09-43

ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ

0:00 Коръәни Кәрим
6:05 Коръән тәфсире
6:25 Көндәлек догалар
6:30 Тыныч лык тәгълимате
6:50 Җиһанда Рамазан ае
7:05 Таян Аллаһка
7:20 Хәзрәткә сорау
7:30 Иман тәме
7:50 Миллият сүзлеге
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар
8:05 Бәхет тулы йорт
8:30 Күңелдән күңелгә
8:50 Шәхесләргә шәрехләр
9:00 Рухи хәзинә
9:15 Гыйбадәте Исламия
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
10:10 Җиһанда Рамазан ае
10:40 Миллият сүзлеге
10:45 Көндәлек догалар
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака
11:00 40 хәдис
11:20 Аллаһның 99 исеме
11:30 Мәчетләребез тарихы
11:40 101 вәгазь
12:00 Өйләгә азан
12:10 Гыйбадәте Исламия
12:25 Миллият сүзлеге
12:30 Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт
14:10 Әхлак баскычлары
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы
14:45 Сөннәт юлы
15:05 Коръән тәфсире
15:25 Көндәлек догалар
15:30 Җиһанда Рамазан ае
15:45 Бәхет тулы йорт
16:05 Миллият сүзлеге
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар
16:20 101 вәгазь
16:40 Күңелдән күңелгә
17:00 Шәхесләргә шәрехләр
17:10 Гыйбадәте Исламия
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака
17:40 40 хәдис
Ахшамга азан, авыз ачу
19:30 Әдәбият күрке әдәп
19:45 Миллият сүзлеге
20:00 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
20:20 Һәр яхшы сүз – сәдака
20:30 Нәниләргә нәсыйхәт
20:35 Пәйгамбәрләр тарихы
20:50 Көндәлек догалар
21:10 Мәчетләребез тарихы
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.)
21:50 Хәзрәткә сорау
22:00 Гыйбадәттә сәгадәт
22:10 Әхлак баскычлары
22:20 Җиһанда Рамазан ае
22:37 Миллият сүзлеге
22:45 Аллаһның 99 исеме
23:00 Коръәни Кәрим

ҖОМГА

0:00 Коръәни Кәрим
6:00 Җомга тәбриге
6:05 Коръән тәфсире
6:25 Көндәлек догалар
6:30 Тыныч лык тәгълимате
6:50 Җиһанда Рамазан ае
7:05 Таян Аллаһка
7:20 Хәзрәткә сорау
7:30 Иман тәме
7:50 Миллият сүзлеге
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар
8:05 Бәхет тулы йорт
8:25 Җомга тәбриге
8:30 Күңелдән күңелгә
8:50 Шәхесләргә шәрехләр
9:00 Рухи хәзинә
9:15 Гыйбадәте Исламия
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
10:00 Җомга тәбриге
10:10 Җиһанда Рамазан ае
10:40 Миллият сүзлеге
10:45 Көндәлек догалар
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака
11:00 40 хәдис
11:20 Аллаһның 99 исеме
11:30 Мәчетләребез тарихы
11:40 101 вәгазь
12:00 Өйләгә азан
12:10 Гыйбадәте Исламия
12:25 Миллият сүзлеге
12:30 Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт
14:10, 22:10 Әхлак баскычлары
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы
14:45 Сөннәт юлы
15:00 Җомга тәбриге
15:05 Коръән тәфсире
15:25 Көндәлек догалар
15:30 Җиһанда Рамазан ае
15:45 Бәхет тулы йорт
16:05 Миллият сүзлеге
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар
16:20 101 вәгазь
16:40 Күңелдән күңелгә
17:00 Шәхесләргә шәрехләр
17:10 Гыйбадәте Исламия 3
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака
17:40 40 хәдис
Ахшамга азан, авыз ачу
19:30 Әдәбият күрке әдәп
19:45 Миллият сүзлеге
20:00 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
20:20 Һәр яхшы сүз – сәдака
20:30 Нәниләргә нәсыйхәт
20:35 Пәйгамбәрләр тарихы
20:50 Көндәлек догалар
21:10 Мәчетләребез тарихы
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.)
21:50 Хәзрәткә сорау
22:00 Гыйбадәттә сәгадәт
22:20 Җиһанда Рамазан ае
22:37 Миллият сүзлеге
22:45 Аллаһның 99 исеме
23:00 Коръәни Кәрим

ШИМБӘ

0:00 Коръәни Кәрим
6:05 Коръән тәфсире
6:25 Көндәлек догалар
6:30 Тыныч лык тәгълимате
6:50 Җиһанда Рамазан ае
7:05 Таян Аллаһка
7:20 Хәзрәткә сорау
7:30 Иман тәме
7:50 Миллият сүзлеге
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар
8:05 Бәхет тулы йорт
8:30 Күңелдән күңелгә
8:50 Шәхесләргә шәрехләр
9:00 Рухи хәзинә
9:15 Гыйбадәте Исламия
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
10:10 Җиһанда Рамазан ае
10:40 Миллият сүзлеге
10:45 Көндәлек догалар
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака
11:00 40 хәдис
11:20 Аллаһның 99 исеме
11:30 Мәчетләребез тарихы
11:40 101 вәгазь
12:00 Өйләгә азан
12:10 Гыйбадәте Исламия
12:25 Миллият сүзлеге
12:30 Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт
14:10 Әхлак баскычлары
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы
14:45 Сөннәт юлы
15:05 Коръән тәфсире
15:25 Көндәлек догалар
15:30 Җиһанда Рамазан ае
15:45 Бәхет тулы йорт
16:05 Миллият сүзлеге
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар
16:20 101 вәгазь
16:40 Күңелдән күңелгә
17:00 Шәхесләргә шәрехләр
17:10 Гыйбадәте Исламия
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака
17:40 40 хәдис
Ахшамга азан, авыз ачу
19:30 Әдәбият күрке әдәп
19:45 Миллият сүзлеге
20:00 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
20:20 Һәр яхшы сүз – сәдака
20:30 Нәниләргә нәсыйхәт
20:35 Пәйгамбәрләр тарихы
20:50 Көндәлек догалар
21:10 Мәчетләребез тарихы
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.)
21:50 Хәзрәткә сорау
22:00 Гыйбадәттә сәгадәт
22:10 Әхлак баскычлары
22:20 Җиһанда Рамазан ае
22:37 Миллият сүзлеге
22:45 Аллаһның 99 исеме
23:00 Коръәни Кәрим

ЯКШӘМБЕ

0:00 Коръәни Кәрим
6:05 Коръән тәфсире
6:25 Көндәлек догалар
6:30 Тыныч лык тәгълимате
6:50 Җиһанда Рамазан ае
7:05 Таян Аллаһка
7:20 Хәзрәткә сорау
7:30 Иман тәме
7:50 Миллият сүзлеге
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар
8:05 Бәхет тулы йорт
8:30 Күңелдән күңелгә
8:50 Шәхесләргә шәрехләр
9:00 Рухи хәзинә
9:15 Гыйбадәте Исламия
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
10:10 Җиһанда Рамазан ае
10:40 Миллият сүзлеге
10:45 Көндәлек догалар
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака
11:00 40 хәдис
11:20 Аллаһның 99 исеме
11:30 Мәчетләребез тарихы
11:40 101 вәгазь
12:00 Өйләгә азан
12:10 Гыйбадәте Исламия
12:25 Миллият сүзлеге
12:30 Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт
14:10 Әхлак баскычлары
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы
14:45 Сөннәт юлы
15:05 Коръән тәфсире
15:25 Көндәлек догалар
15:30 Җиһанда Рамазан ае
15:45 Бәхет тулы йорт
16:05 Миллият сүзлеге
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар
16:20 101 вәгазь
16:40 Күңелдән күңелгә
17:00 Шәхесләргә шәрехләр
17:10 Гыйбадәте Исламия
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака
17:40 40 хәдис
Ахшамга азан, авыз ачу
19:30 Әдәбият күрке әдәп
19:45 Миллият сүзлеге
20:00 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
20:20 Һәр яхшы сүз – сәдака
20:30 Нәниләргә нәсыйхәт
20:35 Пәйгамбәрләр тарихы
20:50 Көндәлек догалар
21:10 Мәчетләребез тарихы
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.)
21:50 Хәзрәткә сорау
22:00 Гыйбадәттә сәгадәт
22:10 Әхлак баскычлары
22:20 Җиһанда Рамазан ае
22:37 Миллият сүзлеге
22:45 Аллаһның 99 исеме
23:00 Коръәни Кәрим

***Намаз һәм авыз ачу вакыты күчә бару сәбәпле, тапшырулар вакыты да бераз үзгәрергә мөмкин**

Казан өчен май аена намаз вакытлары

Көн	Көн Исеме	Иртәнге намаз		Кояш чыга	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы/иф-тар	Ястү намазы
		Сәхәр тәмам	Мәчетләрдә укыла					
01.05.2021	Шим	00:42	02:30	04:00	12:00	16:52	19:22	21:47
02.05.2021	Якш	00:33	02:28	03:58	12:00	16:54	19:24	21:51
03.05.2021	Дүш	00:23	02:25	03:55	12:00	16:55	19:26	21:55
04.05.2021	Сиш	00:10	02:23	03:53	12:00	16:56	19:28	22:00
05.05.2021	Чәрш	23:44	02:21	03:51	12:00	16:57	19:30	21:00
Игътибар! Намаз вакытлары үзгәрә								
06.05.2021	Пәнҗ	01:49	02:19	03:49	12:00	16:58	19:32	21:02
07.05.2021	Җом	01:47	02:17	03:47	12:00	16:59	19:34	21:04
08.05.2021	Шим	01:45	02:15	03:45	12:00	17:01	19:36	21:06
09.05.2021	Якш	01:43	02:13	03:43	12:00	17:02	19:37	21:07
10.05.2021	Дүш	01:41	02:11	03:41	12:00	17:03	19:39	21:09
11.05.2021	Сиш	01:39	02:09	03:39	12:00	17:04	19:41	21:11
12.05.2021	Чәрш	01:37	02:07	03:37	12:00	17:05	19:43	21:13
13.05.2021	Пәнҗ	01:35	02:05	03:35	12:00	17:06	19:45	21:15
14.05.2021	Җом	01:33	02:03	03:33	12:00	17:07	19:47	21:17
15.05.2021	Шим	01:31	02:01	03:31	12:00	17:08	19:49	21:19
16.05.2021	Якш	01:29	01:59	03:29	12:00	17:09	19:51	21:21
17.05.2021	Дүш	01:28	01:58	03:28	12:00	17:10	19:52	21:22
18.05.2021	Сиш	01:26	01:56	03:26	12:00	17:11	19:54	21:24
19.05.2021	Чәрш	01:24	01:54	03:24	12:00	17:12	19:56	21:26
20.05.2021	Пәнҗ	01:23	01:53	03:23	12:00	17:13	19:58	21:28
21.05.2021	Җом	01:21	01:51	03:21	12:00	17:14	19:59	21:29
22.05.2021	Шим	01:19	01:49	03:19	12:00	17:15	20:01	21:31
23.05.2021	Якш	01:18	01:48	03:18	12:00	17:16	20:03	21:33
24.05.2021	Дүш	01:16	01:46	03:16	12:00	17:17	20:04	21:34
25.05.2021	Сиш	01:15	01:45	03:15	12:00	17:18	20:06	21:36
26.05.2021	Чәрш	01:14	01:44	03:14	12:00	17:19	20:08	21:38
27.05.2021	Пәнҗ	01:12	01:42	03:12	12:00	17:20	20:09	21:39
28.05.2021	Җом	01:11	01:41	03:11	12:00	17:21	20:11	21:41
29.05.2021	Шим	01:10	01:40	03:10	12:00	17:21	20:12	21:42
30.05.2021	Якш	01:09	01:39	03:09	12:00	17:22	20:14	21:44
31.05.2021	Дүш	01:07	01:37	03:07	12:00	17:23	20:15	21:45

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

Апрель саны, №4 (309)

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сабирова Ф.И.**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
Электрон адресы: shura@huzur.ru
Телефон: +7 (843) 598-09-42

РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
Камил СӘМИГУЛЛИН;

«Хозур» нәшрият йорты директоры
Ришат ХӘМИДУЛЛИН;
ТР МДННең Шәригать бүлеге җитәкчесе
Булат МӨБАРӘКОВ;
Татарстанның баш казые
Җәлил ФАЗЛЫЕВ;
ТР МДННең Голәмәләр шурасы әгъзасы
Габдулла ӘДҺӘМОВ

Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
Нәшир: «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт).

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2534
Газетага ярты елга язылу бәясе – 170, 04 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 27 нче апрельдә таратыла.
График буенча бу санга 26 нчы апрель көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.